Сезнең өчен түләнгән

Мохтаҗ гаиләләргә махсус пластик карталар бирелә башлаячак. Аның ярдәмендә кибеттән билгеле бер суммага азык-төлек алырга мөмкин булачак. Татарстанда исә кайбер шәһәрләрдә мохтаҗларга бушлай ипи тараталар.

6 БИТ

Бер мәхәббәт тарихы

«Яланаяклы кыз» сериалына – 10 ел

12 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Пәнҗешәмбе | 16.02.2017 | № 16 (5778)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ һӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

Иван Кузнецов:

«ТАТАР КЫЗЫНА ГАШЫЙК БУЛСАГЫЗ, ТЕЛНЕ ТИЗ ӨЙРӘНЕРСЕЗ»

Казан шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Иван Владимирович Кузнецовның татар телен өйрәнә башлавы мәхәббәткә бәйле. «Тормышта бөтен башлангыч – мәхәббәттән», – ди ул.

7 БИТ

П2430 Атналык (пәнҗешәмбе)

1 айга 65 сум 73 тиен
3 айга 193 сум 19 тиен
6 айга 394 сум 38 тиен

Ташламалы бәядән язылып кал!

һәр айның 15 числосына кадәр язылсагыз, газета киләсе ай башыннан киләчәк.

Синең өчен, синең турында!

П2395 Көндәлек (сишәмбе, пәнҗешәмбе, җомга)

120 сум 27 тиен 1 айга
387 сум 81 тиен 3 айга
775 сум 62 тиен 6 айга

Реклама

РЕСПУБЛИКАДА

МӨСЛИМ

Әмәкәй авылында Әфганстан территориясеннән Совет гаскәрләре чыгарылуга 28 ел тулуга багышланган районара чаралар үткәрелде. Анның кысаларында әфган сугышында һәлак булган Илфар Фәррахов, аннан кайткач, арабыздан киткән бертуган Филис, Фаяз Исмәгыйлевләр каберләренә чәчәкләр салынды, өч бертуган Исмәгыйлевләр йортына истәлек тактасы куелды.

КАЙБЫЧ

«Халкым хәзинәсе» исемле фестиваль-конкурсның сайлап алу турында Иске Чәчкаб авылының Наилә Сибгатуллина җитәкчелегендәге иҗат коллективы сәхнәдә бик матур итеп каз өмәсеннән соң кич утыру йоласын сәхнәләштерде. Авылның өлкән яшьтәге абый-апалары һәм яшьләр җырлады, биеде, табышмак әйтеш һәм орчык уены уйнады.

ӘЛКИ

Әлки районында бүген алиментлар буенча бурычлары җыелган 116 кеше исәпләнә. Аларның балаларына 6 миллион сумга якын бурычлары бар. Ул һәм кызларына тиеш булган акчаларны түләп торудан качып йөрүчеләрнең 20се – хатын-кыз. Аларның барысы да ата-ана хокукыннан мәхрүм ителүчеләр.

ӘЛМӘТ

Әлмәтлеләрне наркотик матдәләр куллану-кулланмауларын тикшерәчәкләр. Моның өчен 1,4 млн сум акча тотылачак. Шуның кадәр акчага Әлмәт наркология диспансеры тестлар сатып алачак. Әлеге тестларны мәктәп укучыларын һәм студентларны тикшерү өчен тотачаклар.

ЛАЕШ

Лаеш районы Комлы Ковали урта мәктәбендә ике көн дәвамында Татарстанның белем бирү учреждениеләре җитәкчеләре өйрәнүләр үтте. Директорлар ачык дәресләрдә, семинарларда катнашты.

АКСУБАЙ

Районда «Туган җирем, синең белән горурланам һәм сөенәм» проекты кысаларында җирлеккара эстафета башлана. Аны, район башлыгы Камил Гыйльманов хуплавы белән, районның мәдәният бүлеге оештыра. Проектның максаты – күркәм йолалар, данлыклы якташларыбыз һәм Аксубай җирен таныткан хезмәтчәннәр белән таныштыру.

Яңалыклар район газеталары сайтларыннан алынды.

«Казан каймасы» тарихын бергәләп языйк

«Казан каймасы» төзелешендә катнашкан кешеләр турында **shahrikazan.com** сайтыннан укыгыз

volgatourizm.ru

Бөек Ватан сугышы вакытында Казан шәһәрен саклау максатыннан 1941-1942 елларда төзелгән сак чиге – «Казан каймасы» турында газетабызның узган саннарының берсендә тулы бер мәкалә әзерләгән идек. Быел «Казан каймасы» төзелүгә – 75 ел. Шул уңайдан Татарстанның Архив эше буенча дәүләт комитетында фәнни-гамәли конференция узды.

Архив документларыннан билгеле булганча, Казан каймасын төзүгә республиканың 34 районы җәлеп ителгән. Эш Кайбыч, Апас, Буа, Тәтеш, Спас районнары территориясендә бара. Окоп казу эшендә бик күп халык катнашкан. Алар, нигездә, хатын-кызлардан, яшүсмерләрдән, Казаннан китерелгән студентлар, эвакуацияләнеп килүчеләр һәм предприятие эшчеләреннән торган. Алар казыган ярымбожра рәвешендәге гигант корылманың озынлыгы 331 чакрымны тәшкил итә. Халык иртәдән алып кичкә кадәр окоп казый. Араларында үлеп калучылар да, йогышлы авырулар эләктерүчеләр дә, имгәнүчеләр дә була. Җылы киемнәре, эшләргә кораллары да җитмәгән. Төзелешкә кешеләр генә түгел, трактор, машина, атлар да җәлеп ителгән.

Архивта бу хакта кайбер мәгълүматлар сакланса да, «Казан каймасы» буенча күп нәрсә өйрәнелмәгән. Татарстанның Архив эше буенча дәүләт комитеты җитәкчесе Ирада Әюпова әйтүенчә, әлеге мәгълүмати бушлыкны яшьләр катнашында яңа проект белән тулыландырырга мөмкин булыр иде.

– «Казан каймасы» темасын өйрәнә башлагач, катнашучыларның исемлеге дә юклыгын аңладык. Бары тик бүләкләнүчеләр исемлеге генә бар. Безнең төрле архивларда да мәгълүмат фрагментлар рәвешендә генә сакланган. Яшьләр бу эшләрдә актив катнашып, өлкәннәрнең – әби, бабайларының хатирәләрен җыярга булышсалар, нинди зур эш башкарылыр иде. «Казан каймасы» буенча, яшьләребез туплаган хатирәләрне дә кертеп, китап бастырылыр, – дип тәкъдимнәрен җиткерде Ирада Әюпова.

Кайбыч муниципаль районы башлыгы урынбасары **Рамис Хәялиев** сүзләренчә, «Казан каймасы» төзелеше иң беренче булып алар районында башланган. Кайбыч районының Иске Чәчкаб авылында аларның төп штаблары урнаша. «ШК» журналистлары «Казан каймасы» төзелешенең шаһитлары булган берничә кешене табып, алар белән күрешеп тә кайткан иде.

– Мин 21 яшьлек егетне авыл рәисе итеп куйдылар. Окоп казу турындагы хәбәр килеп ирешүгә, мәктәптә штаб оештырдылар. Авылга Казаннан, районнардан бертуктаусыз халык агылды. Көнелә икешәр йөз кеше килә. Барысын да окоп казырга җибәргәннәр. Минем бурыч – аларны фатирга урнаштыру. Урам буенча йөреп, һәр өйдә күпме кеше яшәвенә карап, капкаларына саннар сугып чыктым. Биш дип язылган икән, анда биш кеше керергә тиеш була. Килүчеләр арасында Гадел Кутуй, Гомәр Бәширов та бар иде, тагын ике язучы барлыгы истә калган. Мин аларны фәкыйрь генә йортка урнаштырдым. Сукыр лампа кертеп бирдем. Шуннан соң Гадел Кутуй «Сукыр лампа» дигән шигырен язган. Окоп казучылар өчен пекарня ачылды, эш кораллары кайтардылар, табиблар китерелде, авырып китүчеләрне кире өйләренә озаттылар. Кич белән өйдә ут яндырырга ярамый иде. Төнлә, чират торып, урамнарны сакладык. Уты булган кешеләргә кисәтү ясала иде, – дип искә ала ул елларны Зиннәтулла бабай Заһидуллин.

Шәһәр кәефе

ӘЛ БАЧРИ ВӘЛИД СӘМИ,
студент:

– Гыйрактан үзем. Бездә җәй айларында эсселек 50 градуска кадәр җитә, кышын -1 градус салкын да булгалый. Россия Президенты Владимир Путин бик көчле лидер. Казан халкы ачык йөзле, милләтләрнең шулай дус яшәве сокландыргыч. Мәчеткә йөрим. Сугышлар булмасын иде. Су чыганаклары һәм туфрак катламы белгечлеген үзләштерәм. Алла боерса, тагын бер елдан университетны тәмамлыйм. Гыйракта балык үрчетү буенча эш башларга хыялланам.

АЗАЛИЯ НУГАЙГУЛОВА,
студент:

– Башкортстанның Әлшәй районында туып-үстем. Уфа табигате белән матур, ләкин Казан шәһәр төзелеше, инфраструктура ягыннан нык алда. Метро һәм җир өсте җәмәгать транспорты яхшы. Баскетбол белән шөгыльләнәм. Казанлылар спорт комплексларына шулкадәр актив йөри. Укудан тыш, эшләргә дә өлгерәм әле. Германиягә туристлык сәфәре ясарга хыялланам. Туган якка еш кайтып булмый, Башкортстанга сәлам!

МАРС ИДИӘТУЛЛИН,
отставкадагы хәрби:

– Казанда шәхси йортыбызда яшәгәнлектән, токымлы тавыклар, индоутка үстерүгә күңел баглаган әле мин. Белоруссиянең Минск шәһәреннән туганнарыбыз, кунакка кайткан саен: «Казанда торак йортларда архитектура юк. Йортларыгыз гап-гади шакмак», – дип тәнкыйтьләп китәләр. Киләсе җәйдә, дуслар белән бергә, Кырымга автосәяхәткә кузгалырга планлаштырып торабыз. Яшьләр китап укысын иде, без лампа яктысында китап укып үстек.

РӘМЗИЯ МУЛЛАХМӘТОВА,
укытучы:

– Казанга Арчадан 1990 елда килдем. Киров районындагы 137нче мәктәптә эшлим. Мәктәп ашханәләрендә балаларны начар тукландыралар, дигән сүз дөрес түгел. Киров районында мәдәният йорты юк. Адмиралтия бистәсен туристлык үзәге итеп төзекләндергәндә, анда мәдәният йорты да төзелсен иде. Халыкара конференцияләр үткәрә торган затлы бина димим, ә пенсионерлар да, зурлар да, укучы балалар да рәхәтләнеп йөрерлек клуб кирәк.

НИЯЗ БИШБАЛТА,
тарихчы:

– Казанда яшәвемә – 45 ел, үзем Буадан. Татарстан башкаласы урамнарында һәм йорт-биналарында татар рухы булмавы борчый мине. Бауман урамы буйлап барсагыз, Европа шәһәре диярсең. Элмә такталардагы язуларның күбесе инглиз телендә. Татар мәктәпләре ябылмасын, алар дәүләт саклавына алынсын иде. Казанда бакча-паркларны төзекләндерү программасын чын күңелдән хуплыйм. Әлеге бакчаларның һәркайсының үз тарихы бар.

Булдыклы кеше эшсез калмый

20 елдан массакүләм мәгълүмат чаралары хезмәткәрләре кирәк булмаячак. Дөресрәге, «иске мәктәп» журналистларына ихтыяҗ бетәчәк, дип хәбәр итә «Яңа һөнәрләр атласы»н төзүче тикшеренүчеләр. Киләчәктә журналистлар берьюлы берничә эш эшләргә: радиопрограмма да әзерли, фильм да төшерә, китап та яза белергә тиеш икән. «Юкка чыгачак» белгечлекләр исемлегенә икътисадчылар, менеджерлар, хисапчылар, юл-патруль хезмәте инспекторлары, тәрҗемәчеләр, архивариуслар, нотариуслар, аналитиклар, табиб-диагноз куючылар, диспетчерлар, турагентлар һәм риелторлар, каскадерлар, экскурсоводлар, шахта эшчеләре, тау сәнәгате эшчеләре, урам себерүчеләр, хат ташучылар, сакчылар да кертелгән.

media.salon.com

Римзил ВӘЛИЕВ,
журналист, җәмәгать эшлеклесе:

– Үз эшләренең осталары беркайчан да эшсез калмый, шул исәптән журналистлар да. Заманга ярақлашкан, технологияләрне үзләштергән тиз эшли белүче журналистлар гел кирәк. Нинди генә һөнәр иясе булсаң да, заман синең алдыңа таләпләрне куеп кына тора. Аягөсте йоклап йөрсәң, булдыксыз булсаң, чынлап та эшсез каласың. Көндәшлеккә сәләтле булырга, үз өстеңдә эшләргә кирәк. Мин иске мәктәп журналисты булсам да, видео да төшерәм, монтажлыйм да, интернетка да эләм, социаль челтәрләрдә дә актив утырам. Эшсезлектән тилмереп утырмыйм, эшләп өлгерә дә алмыйм хәтта.

Надежда СЕКРЕТОВА,
Казан экскурсоводлары ассоциациясе рәисе:

– Экскурсовод хәзер иң популяр һөнәр. Тикшеренүчеләр бу исемлекне ни рәвешле төзегәннәрдер, мин алар белән килешмим.

Алия САФИУЛЛИНА,
туристлык агентлыгы хезмәткәре:

– Хәзер кешеләр елына өчәр-дүртәр тапкыр ял итәргә йөргәндә, безнең һөнәр ничек бетәр икән ул. Кайсы гына илне алма, төп акча чыганаклары – туризм. Туристларны үзләренә җәлеп итү өчен нинди генә ташламалар ясамыйлар. Халык та кризис дип тормый, юлламалар яхшы сатылып тора.

Студентлар укырга да, эшкә дә өлгерә

17 февраль Россия студентлар отрядлары көне буларак билгеләп үтелә. Шул уңайдан Татарстанда «Сүз белән түгел, эш белән!» дигән II республикакүләм эшче яшьләр форумы оештырыла. Делегатлар – 1200 кеше.

Республикабызда 11600 студент җәйге ялларын хезмәт отрядларында үткәрә. Төзелеш, хезмәт күрсәтү өлкәсендә һәм башка эшләрдә эшлиләр, җиләк-җимеш җыялар.

– Студентларның республикага икътисади ярдәме дә зур. Ел саен алар, читтә эшләп, Татарстанга 267 миллион сум акча китерә, – диде Татарстанның яшьләр эшләре һәм спорт министры урынбасары Рөстәм Гарифуллин.

Студентлар хәрәкәте Казан, Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт, Зәй, Бөгелмә, Чистай шәһәрләрендә киң җәелдерелгән. Быелдан аны районнарга да таратмакчылар. Республика студентлар отряды үзәге директоры Ринат Садыйков белдергәнчә, ил буенча Татарстан отрядлары беренче бишлектә бара икән.

Казан дәүләт медицина университетының гомум мәсьәләләр буенча проректоры Зиннур Гәрәев тә студентлар хезмәт отряды ветераны. Студент чагында отрядта киеп йөргән курткасын ул бүген дә саклый.

– 1980 елларда Мәскәүдә Олимпия уеннары барган вакытта, без кырдан помидор җыеп, аларны башкалага ташый идек. Шул вакытта 24 тонна помидор җыйдык. Җәй дәвамында һәр кешегә берәр тонна дигән сүз. Безнең өчен бу зур мәктәп булды. Хәзер мин теләсә кайсы техникада эшли алам. Гаиләләр кордык. Тормыш иптәшемне дә хезмәт отрядларында таптым, – дип искә ала Зиннур Гәрәев.

Хезмәт отрядлары бер үк вакытта белем бирү мәйданы да. Биредә ел саен 200гә якын студент һөнәр үзләштерә.

Проводник булып яки педагогик отрядларда эшләү өчен студентларга вакытлы сертификат бирсәләр, бетончы, ташчы, штукатур-буяучы һөнәри белем кебек бара. Алга таба студент шул һөнәр буенча студентлар отрядыннан тыш та эшли ала дигән сүз бу.

Алисә САБИРОВА.

ТОП – 5

2016 ЕЛ нәтиҗәләре буенча, Татарстан туристларны җәлеп итү өлкәсендә Россиянең иң популяр төбәкләренең беренче унлыгына кергән. Татарстан – алтынчы баскычта. Аңа кадәр урыннарны Краснодар крае, Мәскәү өлкәсе, Кырым, Владимир һәм Приморье өлкәләре бүлешкән. Үткән ел Татарстанда 2,9 млн. турист булган. 2015 ел белән чагыштырганда, сәяхәтчеләр саны 7 процентка арткан.

МАШИНА йөртү таныклыгын Бердәм дәүләт хезмәте порталы аша бик тиз алмаштырырга мөмкин. Бу ресурс ярдәмендә гариза бланкларын тутырырга, кирәкле документлар пакетын җыярга, кабул итүгә язылырга мөмкин. Моннан тыш, 1 февральдән башлап, «Татарстанда дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе машина йөртү таныклыгын ясау һәм тапшыруга гаризалар кабул итә башлады. Ләкин монысы бары тик таныклыкны алмаштырганда, ул урланган яисә югалган очракларда гына тормышка ашырыла.

БЫЕЛ 15 июльдә Пенза өлкәсе Урта Әләзән авылында узачак VIII Бөтенроссия авыл Сабан туеның рәсми сайты ачылды. Сайт Сабантуй2017.рф адресы буенча урнашкан. Урта Әләзән авылы Россиядә иң зур татар авылларының берсе. Биредә 9 меңгә якын кеше яши. Авылда 2,5 мең хуҗалык, дүрт тегермән, май цехы, тегү цехы, йортлар төзелеше буенча цех, мәдәният сарае, 11 мәчет, мәдрәсә, ике урта мәктәп, балалар бакчасы, хастаханә, сырхауханә, 24 кибет, кафе бар. Урта Әләзәндә бәйрәм мәйданы 30 гектарны биләр, бәйрәмгә 35 төбәктән делегацияләр килер, 50 меңнән артык кунак җыелыр дип көтелә.

КИЧӘ Муса Җәлил исемендәге республика премиясе лауреатлары ачыкланды.

Тавыш бирү нәтиҗәсендә иң күп баллны шагыйрь Рәмис Аймәт җыйган. Шулай ук Тинчурин театры артистлары Артем Пискунов белән Резедә Сәләхова, «Иҗади яшьләр академиясе» иҗтимагый оешмасы һәм Башкортстаннан Марат Шәрипов та лауреатлар дип табылган.

Муса Җәлил исемендәге премия ике елга бер тапкыр бирелә. Аның күләме – 200 мең сум.

2017 ЕЛДА Татарстанда 517 млн сумга 5 спорт корылмасы үзәге реконструкцияләнәчәк. Алар арасында Үзәк стадион мәйданы да бар, аңа 107 млн сум тотылачак. Барлык объектлар да 2017 елның 30 июленә әзер булырга тиеш. Мәйданнарны реконструкцияләү 2018 елда узачак футбол буенча Россия Федерациясе чемпионаты программасы кысаларына кергән, өстәмә финанслар – Россия һәм Татарстан бюджетыннан.

КҮРШЕЛӘРДӘ

Башкортстанда балалары туган яшь гаиләләргә 300 мең акча түләнәчәк, дип яза «Татар-информ» агентлыгы. 2017 елдан республикада беренче баласы туган яшь гаиләләргә торак сатып алу өчен берьюлы бирелә торган социаль түләү тапшырылачак. Бу хакта муниципалитет башлыклары белән демография мәсьәләләре буенча киңәшмә вакытында Башкортстан башлыгы Рөстәм Хәмитов белдергән. «Тиздән мин 300 мең сум күләмендә социаль түләү тапшыру турында карарга кул куячакмын, ул бу елның башыннан балалары туган гаиләләрнең тору шартларын яхшырту өчен бириләчәк», – дигән ул.

Чуашстанда яшәүче татарлар милли яңарыш хәрәкәтенең 30 еллыгын күпсанлы чаралар белән билгеләп узарга җыена, дип яза «Азатлык» радиосы. Төбәктәге татар милли-мәдәни мөхтәрияте рәисе Фәрит Гыйбатдинов сүзләренчә, шушы өч дистә ел эчендә Чуашстан татарларының тормышы зур үзгәреш кичерде, милләтнең үсеше шактый алга китте. Уңышыбыз көндәлек эшләүгә бәйле, дини оешмаларда да, милли оешмаларда да үзешчәнлек бетте, җирене җиткереп көндәлек эшләү бар бездә, дигән ул. Әмма әлегә хәл ителмәгән проблемалар да бар. Бүгенгә көнгә кадәр Чуашстандагы татарларның тарихына багышланган саллы гына бер тарихи хезмәт тә, тарихны өйрәнүче галимнәр дә юк.

Мари Эл республикасы Бәрәңге районының Куянково авылында яшәүче Бөек Ватан сугышы ветераны Фәйзрахман Халирахмановка 95 яшь тулган. Сугышта ул – разведчик. Аннан кайткач, колхозны күтәрүгә зур өлеш керткән, авыл советы җитәкчесе булган. Фәйзрахман бабайның хатыны Кәримә әби дә май аенда 95 яшьлек юбилеен билгеләп үтәчәк. Алар 73 ел бергә гомер итеп, тугыз бала үстергән. Бүген аларның 18 оныгы һәм 14 онықчыгы бар.

АТНА ФОТОСЫ

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Иң «тәмле» коллегия

Бер айдан артык барган йомгаклау коллегияләренең иң «тәмлесе», әлбәттә, Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгыныкыдыр. Ишекне атлап керүгә, борынга затлы ризык исе килеп керә. Кайда коймак, кайда казылык, балык, катык... Авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре бүген тамакны гына әсир итмиләр, алар тәкъдим иткән ризыклар күзнең дә явын алырлык. Моннан берничә ел элек кенә, азык-төлекне җитештерә беләбез, матур итеп төреп, бизәп, сатып алучыга тәкъдим итә белмибез, дип әйтә идек, хәзер инде бар да башкача.

Зөлфия ХӘЛИУЛЛИНА

Гомумән, авыл хуҗалыгы тармагы 2016 елгы эш нәтиҗәләре буенча үсештә.

Татарстан – Идел буе федераль округында беренче урында. 8,8 процент авыл хуҗалыгы биләмәләренә ия булып, республика авыл хуҗалыгы товарлары җитештерү буенча Идел буе округында авыл хуҗалыгы продукциясенең 18,2 процент өлеше – безнеке. Россия Федерациясе төбәкләре арасында Татарстан – өченче урында.

Былтыр 4,3 млн тонна ашлык, 2,3 млн тонна шикәр чөгендере, 400 мең тоннадан артык яшелчә уңышы җыеп алынган. Сөт 1770,4 мең тонна күләмендә – Россия субъектлары арасында беренчелектә, сугымга терлек һәм кош ите 484,3 мең тонна – дүртенче урын.

БАР ДА ТИГЕЗ АХИРӘТТӘ ДӘ СОҢ...

Әлеге саннар бөтен республика буенча авыл хуҗалыгы тармагында куелган хезмәтне күрсәтә. Беренче карашка, һәр районның, һәр хуҗалыкның өлеше кергән кебек. Шулай да тырышлык барлык җирдә дә бертөсле түгел, булган мөмкинлекләр дә тулысынча кулланылмый, бу турыда коллегиядә кат-кат әйтелде. Һәрбер күрсәткеч буенча алдынгылар һәм иң арттагылар арасындагы аерма бик зур. Хәтта бер үк табигать шартлары булган бер районда да күрсәткечләр бик тә төрле.

– «Бар да тигез җәннәттә» – дип язган Габдулла Тукай үз чорында. Димәк, ул вакытта да бүгенге кебек тырышлар һәм ялкаулар булгандыр, – диде үзенең чыгышында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов.

Иң беренче сәбәп итеп эшне дөрес оештырмауны, булган мөмкинлекләрне кулланмауны китерде. Яңа технологияләр кулланып җирне карау да җитәрлек дәрәҗәдә түгел. Тотылган чыгымнардан күренгәнчә, бу очракта да картина бик төрле. Җирне кадерләмәсәң, әлбәттә, уңыш та кечкенә. Соңгы елларда бигрәк тә Казанга якын районнарда чәчүлек җирләрне йорт төзелешенә, сәнәгать тармагы өчен күчерү очраклары еш күзәтелә.

– Җирне таратырга ярамый. Бетә бит ул җир. Чит илләрдә бу мәсьәләдә бик сак эш итәләр, бездә исә җирне теләсә ничек күчерәләр, – дип канәгатьсезлеген белдерде Президент.

Коллегиядә һәр ел саен терлек санын киметүгә зур шелтә бирелә. Шулай да вазгыять әллә ни үзгәрми. Чистай районында мөгезле эре терлек саны 3653 башка кимегән, 100 гектар чәчүлек җиргә 13 баш терлек туры килә. Кукмарада, киресенчә, 2340 башка арткан һәм 100 гектарга 33 баш терлек туры килә.

– Сез аңлагыз, сөт – төп табыш бирә торган тармакларның берсе, авыл хезмәтчәннәренә хезмәт хакы башлыча сөттән кергән акчадан түләнә, – диде Рөстәм Миңнеханов бу уңайдан.

Хезмәт хакларына килсәк, Тукай районында уртача хезмәт хакы – 31900 сум, ә Кама Тамагында – 13100 сум. Республика буенча уртача хезмәт хакы – 18700 сум.

«БЕЗГӘ ФИШМАННЫ ҖИБӘРЕГЕЗ»

– Узган ел коллегиядә чыгыш ясаган Арча районындагы коллегам кебек шигырь сөйләү осталыгым юк, шулай да эш нәтиҗәләребез куанычлы, – дип башлады үзенең чыгышын Кукмара районы Вахит хуҗалыгы җитәкчесе Нәфыйк Хөсәенов.

Хуҗалык – республикадагы иң алдынгыларның берсе. 1700 баш савым сыерлары гына бар, табышның 93 процентын терлекчелектән алалар. Соңгы ике елда үз акчаларына 545 млн сумлык төзелеш эшләре башкарганнар. Вахитка кергән авыллар һәрвакыт зур кайгыртучанлык тоеп яшиләр. Мәктәп, балалар бакчалары, су юллары, күперләр, чишмәләр – боларның барысын да хуҗалык карый. Узган ел авылның социаль тормышына һәм аерым кешеләргә ярдәм итү өчен генә дә 8 млн сум акча тотылган. Ун ай элек, җитәкченең үзе әйтмешли, ихтыяри мәҗбүри «Сөт иле» карамагында булган хуҗалыкны да биргәннәр. Ул вакытта уртача савым 6 литр булса, бүген әлеге фермада бер сыердан 19 литр сөт савалар.

– Яңа сыерлар алдыгызмы әллә? – дип сорады министр.

– Шул ук сыерлар, бары тик яхшырак ашаттык, тәрбияләдек, – диде Нәфыйк Хөсәенов. Һәм үзенең гозерен дә җиткерде: – Тырышып эшләгән кешенең кешечә ял итәсе дә килә. Мәдәният йорты каршында ял паркы төзисебез килә. Рөстәм Нургалиевич, безгә Наталия Фишманны кунакка җибәрегез әле. Бер авылда да булмаган ял паркын тәкъдим итсен, чыгымнарның 20 процентын үзебез күтәрергә әзер.

Нәфыйк Хөсәеновның чыгышыннан соң Президенттан күпләргә шелтә эләкте.

– Син булмый дигән хуҗалыкта ун ай эчендә савымны өч тапкыр арттырганнар. Менә була икән бит, – диде ул «Сөт иле» генераль директоры Марат Моратовка. – Акланып торма. Акланырга түгел, бөтен резервларны кулланып эшләргә кирәк.

Аннан Питрәч районы башлыгы Эдуард Дияровны бастырды.

– Күрәсеңме, бер Вахит хуҗалыгы тулаем Питрәч районы саткан хәтле сөт сата. Әле саву гына түгел, аны сатасы да бар. Кукмара районы Питрәч кебек Казан артында түгел. Парк төзергә, әлбәттә, булышырга кирәк. Шулай хезмәт куйган кешеләргә без бер парк кына төзеп бирергә тиештер бит инде, – диде Рөстәм Миңнеханов.

2016 елда авыл хуҗалыгы тармагында уртача хезмәт хакы (сумнарда)



Авыл хуҗалыгы күрсәткечләре буенча Татарстан районнары рейтингы (2016 ел)

№	2015 елга үзгәреш +, –	Район
1	0	Әтнә
2	0	Балтач
3	+ 1	Актаныш
4	– 1	Тукай
5	0	Саба
6	+ 1	Буа
7	– 1	Кукмара
8	+ 2	Зәй
9	+ 4	Кайбыч
10	+ 2	Яшел Үзән
11	– 3	Апас
12	+ 11	Чүпрәле
13	+ 5	Алабуга
14	+ 15	Тәтеш
15	– 4	Арча
16	+ 3	Сарман
17	– 8	Әлки
18	+ 7	Нурлат
19	– 3	Мамадыш
20	0	Биектау
21	– 7	Түбән Кама
22	– 5	Ютазы
23	– 8	Теләче
24	– 3	Б.Бистәсе
25	– 3	Питрәч
26	+8	Азнакай
27	0	Чистай
28	– 2	Алексеевск
29	– 5	Лаеш
30	– 2	Яңа Чишмә
31	– 1	Баулы
32	+ 1	Лениногорск
33	+2	Минзәлә
34	– 2	Әгерҗе
35	+ 1	Аксубай
36	+ 4	Мөслим
37	0	Спас
38	– 7	Югары Ослан
39	– 1	Бөгелмә
40	+ 1	Әлмәт
41	+ 1	Минзәлә
42	– 3	Кама Тамагы
43	0	Чирмешән

Президент үз чыгышында шәхси хуҗалыклардагы терлек саны кимүгә карата да фикерен җиткерде. Моннан ун ел элек авылларда 100 шәхси хуҗалык 54 сыер тоткан булса, бүген республика буенча 100 хуҗалыкка 28 терлек туры килә. Лаеш районында бу сан – 6, Питрәчтә – 11.

Марат Әхмәтов чыгыш ясар алдыннан экранда «Сәүдә кешене – бай, авыл хуҗалыгы иркле итә» дигән сүзләр чыкты. Аякларына нык итеп басып торган, бер дигән уңышларга ирешкән хуҗалыкларның эш тәҗрибәсе белән танышканнан соң бу сүзләрнең дөреслегенә инанасың. Алар кредитка да, хәтта табигать шартларына да бәйле түгел.

Валерий Шатновны редакциягә үзен солдат аналары комитеты рәисе дип йөрткән Галина Чумаченкова алып килде. Ир менә инде өченче ай урамда яши икән. Бөтен документларын урлаганнар. Галина ханым яңа паспорт ясатырга ярдәм иткән. Ә полис алуда авырлыклар килеп чыккан, аның өчен теркәлү урыны кирәк. Валера – өченче группа инвалид. Юл һәлакәтендә аяклары зәгыйфьләнгән. Инвалидлык буенча пенсия ала. Тиздән аңа кабат медицина тикшерүе узарга кирәк, әмма сырхауханәдә полиссыз кабул итмиләр. Тиешле вакытында махсус комиссия тикшерүе узмаса, Валера группада булып саналмаячак, димәк, пенсиясез дә кала дигән сүз...

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

«Нигә мине бу дөньяга тудырдылар икән?!»

Эльвира МОЗАФФАР

Батыршин урамындагы чүплекләрнең берсе. Чүплектән ерак түгел җылылык торбалары уза. Гаражларга якынрак торбалар өстенә таш плитәләр түшәлгән. Плитәнең бер читыннан матрас күренеп тора. Бу – Валераның яшәү урыны. Ир плитә астына шуышып кереп йоклый. Торба җылысында ризыгын да җылыта, киемнәрен дә киптерә. Шулай да Валераны бомж дияргә тел әйләнми. Кырынган, чиста киенгән үзе.

– 8 мең сумлап пенсия алам бит. Әле менә кичә генә Мәскәү базарыннан 1500 сумлык киендем. Ач торганым юк, – ди.

Эшкә дә урнашкан. Бер кибеттә җыештыручы булып эшли. Көненә 200 сум тирәсе түлиләр икән.

Валераны бу тирәдә белмәгән кеше юк. Гараж хуҗалары, чүп түгәргә килүчеләр дә, Галина ханым да ашарга китерә. Ул үзеннән олыракларга «әти», «әни» дип дәшә. «Дуслар туганнарга караганда да якынрак була дип уйламый да идем», – ди. Баштарак бик ачыларга теләмәсә дә, шоферыбыз тәмәке белән бүлешкәннән соң, Валера безгә язмышын сөйләде.

Валера Шатнов балалар йортында тәрбияләнгән. Ике яшьлек чагында аны уллыкка алганнар. 18 яшенә кадәр бу хакта белми яшәгән егет. Белгәч, чын дөреслекне бик авыр кичергән.

– Үпкә дә булмады кебек, әмма өйдә дә каласым килмәде. Әти-әниемә мине аякка бастырганнары өчен бик рәхмәтле. Аларны бик яратам. Өйдән чыгып киткәндә автобуста үкси-үкси елаганымны гына хәтерлим, – дип искә ала ул көннәрне ир.

Берара ул үз әти-әнисен табу уе белән яна. Тик алар кайчандыр яшәгән баракны җир белән тигезләгәннәр, әти-әнисенең кая күченеп киткәнен берәү дә белми. Ә әтисенең озак еллар төрмәдә утырганлыгы, әнисенең эчкече икәнлеге, икесенең дә ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгәннәре ачыклангач, Валера бу уеннан кире кайта.

Валераның кушаматы – Боксер. Яшь чагында бокс белән мавыккан. Хәзер ябык кына гәүдәле бу ир-атның кайчандыр 72 килолы булганына ышанып та булмый. Таш салучы һөнәрен үзләштергән, 4нче разрядлы пешекче дә.

21 яшендә өйләнгән. Хатынының әти-әниләре белән яшәгәннәр. Тик озак тормый, хатыны үлеп киткән. Балалары булмаган. Валера вакытлыча фатир алып яши башлаган. Хәзер хатынының әти-әнисе дә бакыйлыкка күчкән инде. Йортларына да башка кешеләр хуҗа булганнар.

Кабат өйләнергә талпынып караса да, тормышы җайланып китә алмаган. Хәерчегә җил каршы дигәндәй, 2008 елда машина астына эләгеп, аяксыз да калган.

– Аякларны 12 җирдән текләр. Шулай да таякка таянып булса да йөрергә өйрәндем. Менә эш кенә таба алмыйм. Хәтта караулычы итеп тә алмыйлар. Йөгерә алмыйм шул, – ди, елмаеп.

Кайда ничек көн күрә ала, шулай яши башлый Валера. Акчасы бар икән, җылыда куна. Юк чагында, йорт подвалларында, чормаларда яши. Менә инде өч ай урамда, торбалар өстендә көн күрә. Аның белән сөйләшеп басып торган арада да аякка салкын керде...

– Матрасым белән ябынам, торба җылыта, – диде Валера, мин сикергәли башлагач. –Хәер, яңа ел алдыннан 30 градуслы суыкларда аяк бармагымны өшеттем. Хәзер менә даруханәдән мазьлар алып, үз-үземне дәвалыйм, көн дә аягымны майлап бәйлим. Монда озак торырга җыенмыйм. Җәй көне Аккош күленә күченәм. Йортсыз кешеләрнең күбесе җәен шунда яши. Бу еллар миңа күп нәрсәне аңларга өйрәтте. Акчаң булса, дусларың һәрчак булачак. Дуслар булса үлмисең. Бары үз әти-әниемә бер үпкәм генә бар: нигә дип мине бу дөньяга тудырдылар икән?!

Казанда яшәр урыннары булмаганнар өчен вакытлыча яшәү урыны белән тәэмин итә торган приютлар бар. Без, редакция ярдәме белән, Валераны шундыйларның берсенә урнаштырмакчы идек. Тик ул кискен каршы килде. «Минем режим белән яшисем килми. Анда тәмәке тартырга ярамый, пенсияне дә бирмәсләр. Юк, миңа ирек кадерлерәк», – диде.

Уллыкка алган әти-әнисе белән бүген дә аралаша үзе. Тик алар янына кайтырга уңайсызлана.

– Ир-ат башым белән ничек инде алар торагына дәгъва кылыйм? Анда хәзер үз уллары гаиләсе белән яши. Әти авыр хәлдә, операция кичерде. Мин аларга үземнең урамда яшәвем турында әйткәнем дә юк. Борчылсым килми. Өч бертуганым да бар, бер апам Мәскәүдә яши дип беләм. Тик үз тормышымны үзем җайларга тиешмен. Кемнәргәдер ярдәм сорап барганчы, урамда үлүем яхшырак, – ди.

ПОЛИС БУЛАЧАК

Без Валерий Шатновка полис алырга ярдәм итәргә булдык. Аны алу өчен кая гына мөрәҗәгать итсә дә, теркәлү урыны булмаганга кире борганнар. Хәлне аңлатканнан соң, «Ак Барс-Мед» иминиятләштерү компаниясе безнең хәлгә керде.

– «Россия Федерациясендә гражданнарны медицина иминиятләштерүе турында»гы закон нигезендә, теркәлү урыны мәҗбүри медицина иминияте полисы алу өчен таләп ителгән төп шарт булып саналмый. Шуңа да Валерий Шатнов теркәлү урыны булмаса да, паспорт, шәхси лицевой счетның иминият номеры (СНИЛС) белән «Ак Барс-Мед» компаниясенең теләсә кайсы бүлегенә мөрәҗәгать итә ала. Бу эшне аның өчен башка кеше дә эшли ала. Дөрес, бу очракта, безнең рәсми сайтта күрсәтелгәнчә, ышанычнамә кәгазе язарга туры киләчәк, – дип аңлатты «Шәһри Казан»га «Ак Барс-Мед» иминиятләштерү компаниясенең аңлату һәм аналитика бүлеге җитәкчесе Наталья Страшко.

Кызганыч, боларны ачыклап, Валерий Шатновка кире кат-кат шалтыратсак та, ул әлегә телефонын алмады. Шулай да без бу мәсьәләне контрольдә тотачакбыз, сезгә дә хәбәр итәрбез, хөрмәтле укучылар.

Кызыксындырган сорауларыгызны редакциягә (843) 562-50-03, 8(917) 851-69-62 телефоннары аша җиткерә аласыз.

Без яши торган Шамил Усманов урамы, 8 нче йортта подъезд җыештыру буенча бәхәс чыкты. Кайберәүләр, идән юучыга бирергә акчабыз юк, үзебез җыештырабыз, ди. Ә икенчеләренең идән юасы килми, акча гына түлиселәре килә. Подъезд идәне юыла юыла, юылмаса – юк. Безгә моны ничек хәл итәргә инде?

Илдар МӨХӘММӘТҖАНОВ, Казан.

Константин ПЛАТУХИН, Казан шәһәренең Мәскәү районы торак-коммуналь хуҗалыгы идарә компаниясенең төзекләндерү бүлеге инженеры:

– Йортта яшәүчеләр, идән юучы кирәк дип, имза җыярга тиеш. Халыкның 60-70 проценты имза куйса, без аларның гаризаларын подряд оешмасына җибәрәбез. Идән юучыга акча күләме фатирның квадрат метрыннан чыгып билгеләнә. Ул исәп-хисап кәгазендә чагылачак.

Улым бик еш салкын тиеп авырый. Пневмония дигән диагноз куйдылар. Танышларым, «Пневмо 23» яки «Превенар 13» дигән прививка ясатып карарга киңәш итте. Аны сырхауханәләрдә бушка ясыйлармы? Кайсы вакцина яхшырак?

Алсу ГАЛИМОВА, Казан.

Татарстанның Сәламәтлек саклау министрлыгының матбугат үзәге:

– Пневмококк инфекциясенә каршы вакцинация бер яшькә кадәрге балаларга профилактик прививкалар календаре кысаларында ясала. Риск төркеменә кергәннәр (2-5 яшьлек балалар, еш авыручы олы кешеләр, хәрби хезмәткә алынучылар, хроник авыру белән авыручы 60 яшьтән узганнар) прививка эпидемик күрсәткечләр календаре кысаларында вакцинациләнә. Бер яшькә кадәрге сабыйларга «Превенар 13» вакцинасын ясыйлар, 2-5 яшьлекләргә медицина учреждениесе заказ биргән вакцинаны кадыйлар. Олы яшьтәгеләр һәм хәрби хезмәткә алынучыларга – «Пневмо-23». Прививка үзегез теркәлгән сырхауханәләрдә бушка ясала. Кайсы вакцина яхшырак дигәндә, кайсысын ясарга икәнен табиб хәл итә.

Кызыма мәктәптән физкультура дәресенә чаңгылар алып килергә кушканнар. Алып килмәсәгез, «икеле» куябыз, дигәннәр. Чаңгысы булмаганга, кызыма «өчле» куеп кайтарганнар. Без чаңгылар сатып алырга тиешме һәм укытучының «икеле» куярга хакы бармы?

Исемемне күрсәтәсем килми, Казан.

Гөлнара ГАБДРАХМАНОВА, Татарстанның мәгариф һәм фән министры урынбасары – мәгариф өлкәсендә күзәтүчелек һәм контроль департаменты җитәкчесе:

– Укучыларны чаңгы белән тәэмин итү мәктәп компетенциясенә керә. Чаңгысы булмаган өчен педагогның укучыга «икеле» куярга хакы юк.

Сезнең өчен түләнгән

Россиянең Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы аз керемле гаиләләр өчен яңа социаль программа эшләгән. Шуның кысаларында билгеле бер категория гражданнарга махсус пластик карталар биреләчәк. Андагы акча эквиваленты белән 1400 сумга тәңгәл булган бонуслар ярдәмендә кибеттән ит, сөт, балык, күкәй, җиләк-җимеш, яшелчә алып булачак. Әмма ике шарт белән: әлеге акчага тәмәке һәм спиртлы эчемлекләр алмаска һәм продуктлар үзебездә җитештерелгән булырга тиеш. Бу үзенә күрә ике куянның койрыгын тоту була: аз керемлеләргә дә булышалар, җирле җитештерүчеләргә дә теләктәшлек күрсәтәләр. Пластик карточканы орлыклар, үсентеләр яки терлеккә азык алганда да кулланырга була. Документтан күренгәнчә, ай буена кулланылмаган бонуслар икенче айга күчми, яна икән. (Акча җиткерә алмаучыларның бонуслары кулланылмыйча калырмы икән?!)

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА

bahetle.com

Татарстанда 300 меңләп кеше фәкыйрьлек чигендә яши, дип яза kommersant.ru. Бу – республика халкының 7,6 проценты дигән сүз. Аларның кереме 8077 сумнан да кимрәк. 2016 елда татарстанлыларның акчалата керемнәре 3,3 процентка кимегән. Татарстан халкының уртача айлык кереме 2016 елның гыйнвар-ноябрендә 31,7 мең сум тәшкил иткән. 2015 елда ул 32,16 мең сум булган. Татарстан халкы кеременең күп өлешен азык-төлеккә тота.

АМЕРИКА ТӘҖРИБӘСЕ

Сәнәгать һәм сәүдә министры Денис Мантуров сүзләренчә, әлеге проект дөньяның бик күп илләрендә гамәлгә ашырыла. Безнекеләр Америка тәҗрибәсен кулланырга булган. Америкада ул инде илле ел гамәлдә. Уртача һәр кешегә анда аена 130 долларга талон бирелә. Безнең акчалар белән исәпләгәндә, ул 7540 сум булып чыга.

Министрлык тәкъдим иткән программаны Икътисади үсеш министрлыгы да хуплаган. Финанслар министрлыгы белән берлектә, программаны ахыргача эшләп бетерәсе генә калган. Ведомстводагылар, карточкалар адреслы булачак, аларны социаль хезмәтләр бирәчәк, дип ышандыра. Росстат мәгълүматлары буенча, мохтаҗлар исемлегенә ил буенча 21 миллионнан артык кеше кергән. Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы яңа программа өчен 2017 елда 70 миллиард сум акча тотарга уйлый, әмма бу акчалар 21 миллион кеше өчен җитмәячәк. Шуңа да иләк аша кат-кат уздырылачаклар. Ә ул кемнәргә эләгәчәк соң? Татарстанның Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгыннан алынган мәгълүматлардан күренгәнчә, кеше башына туры килгән яшәү минимумы һәр категория өчен төрлечә. Министрлар кабинеты карары нигезендә, 2016 елның дүртенче кварталында яшәү минимумы, уртача алганда, 8108 сум дип билгеләнгән. Эшләүче кешеләр өчен ул – 8657, пенсионерларга – 6644, балаларга – 8027 сум.

ИДЕЯСЕ ӘЙБӘТ ӘЙБӘТЕН...

Татарстан Дәүләт Советының экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты рәисе Таһир Һадиев «социаль ярдәм адреслы булганда, әлеге программа чынлап та нәтиҗәле булачак» дигән фикердә.

– Әлеге система иң бай илләрдә дә бар. Аз керемле гаиләләргә ярдәм кулы сузу – төп бурычларның берсе. Программаның идеясе әйбәт, әмма аны гамәлгә ашыру механизмнарын яхшылап уйлап бетерәсе бар. Ашыгу – шайтаннан дигән гыйбарә бар бездә. Мондый эштә ашыгу кирәкми. Халыкка сыйфатсыз товар тәкъдим ителмәсен, коррупциягә дә урын калмасын, – ди ул.

Дәүләт Советының икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты рәисе урынбасары Марат Галиев сүзләренчә, адреслы электрон карточкалар булдыру идеясе юктан гына барлыкка килмәгән.

– Мохтаҗларның саны соңгы елларда артты, аларга һичшиксез ярдәм күрсәтелергә тиеш. Хөкүмәт тә аларны яклауны үзенең бурычы итеп күрә. Бонусларны да нәкъ менә продуктлар алуга тоту шарты да уйланып эшләнгән. Җирле җитештерүчеләрне дә күз алдында тотканнар. Бу – дәүләт заказы дияргә була. Аларны да яклауның бер гарантиясе булып тора. Әмма программаның тискәре яклары да юк түгел. Билгеле бер продуктлар гына алырга тиеш булгач, аларның сыйфаты да начарланырга мөмкин. Тагын бер проблема чыкмагае, ул да булса – продуктларга бәя күтәрелү. Монополистлар, сүз куешып, бәяне дә күтәреп куярга мөмкин бит, – ди ул.

Яңа программа турындагы фикерен сорап, без Казан илкүләм тикшеренү-технология институтының икътисад кафедрасы доценты, икътисад фәннәре кандидаты Булат Бакиевка да шалтыраттык.

– Яңа карточка системасының никадәр уңышлы булу-булмавы турында әйтергә иртәрәк. Программаның бөтен детальләре дә безгә билгеле түгел. Миңа калса, анда күп нәрсә уйланылып бетмәгән кебек. Аерым алганда, оештыру процессы сораулар тудыра. Аның өчен документларны җыя, өйрәнә, тикшерә торган махсус инфраструктура, штат булдырырга, җиһазлар сатып алырга кирәк. Ә түләүләрнең күләме бик аз, бер кешегә аена 1200 сум. Бу системаны эшләтеп җибәрү өчен генә дә хөкүмәткә күп акчалар тотарга туры киләчәк. Шуңа да аз керемле халыкка ярдәм итүнең гадирәк схемасын уйлап табарга кирәк. Әйтик, аларның эш хакыннан тотып калына торган акчаларының, ягъни керемгә салымның күләмен киметергә була, – диде ул.

ИСКЕ ЯҢА КАРТОЧКА

Карточка системасы яңалык түгел. Беренче тапкыр ул Беренче бөтендөнья сугышы чорында кертелә. Большевиклар вакытында кызылармиячеләр, эшчеләр, шахтерлар, тимерьюлчылар иң яхшы паекларны алган. 1929 елда СССРда ипине карточка белән генә алып булган. 1930 елда инде башка төр товарларны алу өчен дә карточка кирәк булган. 1941 елда Мәскәүдә һәм Ленинградта тагын карточка системасы кертелә. 80нче еллар башында да талоннар кулланылды. 1993 елга кадәр халык аракы, шикәр, чәй, тәмәке, ярма, сабын, кер порошогын шул талон белән алды. Буш кибет киштәләрен, су буе чиратларны әле дә хәтерләүчеләр күптер. Талонның үзен алыр өчен дә чират була иде. Ул вакыттагы талоннар акчаны алыштырмады, дефицит товарны алу мөмкинлеген генә бирде. Акча бар, аны алырга әйбер юк иде бит. Хәзер дә бар ул талоннар, әйтик, «Бәхетле» социаль ашханәләрендә аз керемле гаиләләр талоннар белән бушка туклана. Кулинария производствосы директоры урынбасары Лилия Габдрәшитова «ШК»га сөйләгәнчә, социаль ашханәләр Казанда – алтау һәм Нократ Аланында – бер.

– Ашханәләр 2006 елдан эшли башлады. Аларда 1120 кеше туклана, барысы да аз керемле гаиләләрдән. Исемлекләрен социаль яклау бүлекләре булдыра. Талоннарны да ай башында шуннан алалар, – ди ул.

ТАЛОН КЕРТМИЧӘ БУЛМЫЙ

Түбән Каманың җәмигъ мәчетенә бер эшмәкәр көн дә 20 ипи калдырып китә. Пенсияләре аз әби-бабайлар, мохтаҗ кешеләр яңа пешкән икмәкне сөенә-сөенә ала. Мәчетнең имам хатибы Йосыф хәзрәт Дәүләтшин сүзләренчә, алга таба 50шәр ипи китертү уе бар, әмма ипи өләшү өчен махсус талон кертми булмый.

– Тәртип дигән нәрсә бетте. Ипи алырга дип бирәр сәгать алдан киләләр. Икмәк китерүче егетнең каршына чыгып басалар. Кемдер үзенә генә түгел, күршегә дә дип алган була. Контрольгә саласы иде бу эшне. Мин моны талон системасы белән хәл итеп була, дип уйлыйм. Һәр микрорайонның җитәкчесенә чыгып, йорт өчен җаваплы кешеләр белән берлектә, мохтаҗларның исемлеген булдырасы иде, – ди ул.

Иван Кузнецов:

«Татар кызына гашыйк булсагыз, телне тиз өйрәнерсез»

Казан шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Иван Владимирович Кузнецовның татар телен өйрәнә башлавы мәхәббәткә бәйле. «Тормышта бөтен башлангыч – мәхәббәттән», – ди ул.

Иван Кузнецов кызы, хатыны Алсу һәм аның әти-әнисе белән.

Эльвира МОЗАФФАР

– Иван Владимирович, татар телен кайчан, ничек өйрәнә башладыгыз?

– Мин татар кызына гашыйк булдым. Хатыным Алсу милли гореф-гадәтләрне, традицияләрне хөрмәт иткән татар гаиләсендә үскән. Әнисе – Казан кызы, әтисе – Кукмарадан. Аларны әти, әни дип атыйм. Безне Кукмарага әтинең төп нигезенә Сабан туена чакырдылар. Әтиләр – өч малай. Нигездә әтинең әнисе – әби, татарлардагы гадәт буенча, төпчек улының гаиләсе белән яши. Әби – авылның хөрмәтле абыстае. Безне бик җылы кабул иттеләр, теләнне йотарлык тәмле ризыклар өстәл тулы: итле борай бәлеше, өчпочмак, гөбәдия, какланган каз, пешкән каз һәм тагын бик күп төрле тәм-томнар иде. Әти туганнарын минем белән, «Яраткан киявем – Иван», – дип таныштырды. Минем исемем рус телендә әйтелгән бердәнбер сүз булды бугай бу очрашуда. Аралашу бары тик татар телендә барды. Аннан Сабан туена киттек, анда да искиткеч күңелле булды, кайтышлый, Алсуларның туганнарына, әтинең дусларына, якыннарына кердек. Һәр йортта безне ачык йөз, мул өстәл, җылы сүз белән каршы алдылар. Икенче юлы кайтканда, мине шулай кабул иткән кешеләргә татар телендә җавап бирә алырлык итеп өйрәнергә кирәк телне, дигән карарга килдем.

– Рус кешесенә татар телен өйрәнү кирәк дип уйлыйсызмы?

– Татар халкында «Телләр белгән – илләр гизгән» дигән мәкаль бар. Күбрәк тел өйрәнгән саен, тормышны тирәнрәк, күпьяклырак танып-беләсең, карашың киңәя. Без яшәгән глобализация чорында телләр белү ул – ихтыяҗ.

Ә сезнең соравыгызны мин «Татарларга татар телен белү кирәкме?» – дип куяр идем дә, «Һичшиксез», – дип җавап бирер идем. Кайчандыр киң таралган, актив кулланылышта булган телләрнең илләр арасында чикләр бетерелгән, күп полярлы дөнья шартларында юкка чыгулары мәгълүм факт. Ә телләрне ничек саклап калырга мөмкин соң? Иң беренче чиратта туган телдә гаиләдә сөйләшергә тиешләр дип саныйм. Юкка гына туган телне татарлар, бик төгәл билгеләп, ана теле дип атамыйлар. Бөек татар шагыйре Габдулла Тукай бу турыда бик матур юлларын язып калдырган:

«И туган тел, и матур тел,
Әткәм-әнкәмнең теле...»

Хатыным Алсулар гаиләсендә барысы да ана телен яхшы беләләр. Алсу әти-әнисе белән дә, балалар белән дә татарча сөйләшә.

– Татар теленә өйрәнгәндә, нинди кыенлыклар белән очраштыгыз?

– Татар теле – матур, йомшак, көйле, камил, төгәл кагыйдәләргә нигезләнгән тел. Минем өчен иң авыры – бер-бер артлы килгән кушымчаларның чикләрен, тәртибен, мәгънәләрен аңлау булды. Мисал өчен, «урамнардагыларныкынмыни, әниләребезнекедәй, килештерәләштергәлиләр» кебек сүзләрдәге кушымчаларны билгеләп һәм аңлап бетерү җиңел эш түгел. Ә «укып йөри, яшәп ята, егыла яздым, кычкырып җибәрде» кебек аналитик фигыльләрне алыйк, болай итеп татарлар гына әйтә ала, бик кызыклы формалар бит.

– Татар телен өйрәнүдә сезнең уңышларыгыз?

– Фикеремне аңлатырлык дәрәҗәдә сөйләшәм, диалог алып бара алам. Татар кешесе шактый кызу сөйләшә, шул темп артыннан куып кына җитә алмыйм.

– Телне тиз өйрәнүегезнең сере нидә?

– Татар кызына гашыйк булсагыз, бу хис сезгә телне үзләштерүдә төп этәргеч булыр. Көнегезне, минем шикелле, эшкә кадәр иртәнге сәгать җиде-сигездә татар телен өйрәнүдән башларсыз. Татар халкы әйткәнчә, мәхәббәт таулар күчерә. Монысы шаяру катыш, әлбәттә. Телне бары тик аралашу, сөйләшү аша үзләштереп була, сүзләр сөйләм вакытында гына истә кала. Шуңа күрә мин татарчага күчәргә мөмкин булган һәр очрактан файдаланырга тырышам. Әнигә, әтигә шалтыратканда, татарча гына сөйләшәм. Алсу белән сөйләшкәндә, өйрәнгән сүзләрне сөйләмгә кертергә тырышам.

– Телне әле өйрәнә генә башлаган кешеләргә нинди киңәшләр бирер идегез?

– Телдәге матур әйләнмәләргә игътибар итегез, исегездә калдырырга тырышыгыз. Татар теле, әйткәнемчә, матур тел, ул җыр шикелле, күңелгә үтеп керә. Татар телендә сөйгәненә, якыннарыңа мөрәҗәгать итә торган «җаным, җанашым, җан кисәгем, бәгырем, акыллым, матурым, аккошым, җимешем, ахагым» яки туганлык мөнәсәбәтләрен чагылдырган «алма апа, тәти апа, чәчәк апа, дәү абый, кечкенә абый, тәти абый, әнкәем, әткәем, әбекәем, бабакаем» кебек искиткеч җылы, ягымлы сүзләр бар. Телнең шундый матурлыгын тойсаң, ул күңелгә үтеп керә, аны өйрәнәсе килә. Телне кемдер, ниндидер шартлар мәҗбүр иткәнгә түгел, бары тик аны яратканда гына өйрәнеп була.

– Татар әдипләренең әсәрләре белән танышмы сез?

– Әйе. Алар миңа телне өйрәнгәндә булыша. Хөрмәтле яраткан укытучым Рәсимә Равиловна Шәмсетдинова (миңа татар телен ул өйрәтә) дәресләрнең берсендә әни турында язылган шигырь алып килгән иде, аның түбәндәге юллары күңелгә аеруча кереп калган:

Иң сабыр йөрәк –
Синең йөрәгең,
Иң изге теләк –
Синең теләгең,
Әни!

Үземнең әниемне бик нык яратам, аңа барысы-барысы өчен дә чиксез рәхмәтлемен. Һәр көнемне аңа шалтыратудан, хәлләрен белүдән башлыйм. Ул минем тормышымда иң кирәкле, иң якын, иң мөһим кешеләрнең берсе. Шуңа күрә әни турында шулай тирән итеп язган автор турында күбрәк беләсем килде. Рәсимә Равиловна миңа шигырьнең авторы – көчле ихтыярлы, талантлы язучы, шагыйрь Фәнис Яруллинның каталаулы язмышы турында сөйләде, иҗаты белән тирәнрәк таныштырды. Аның белән якыннан танышу теләге туды. Фәнис Яруллинның адресын таптым, күчтәнәчләр алдым да киттем. Хатыны да, үзе дә бик җылы кабул иттеләр. Язучы рус кешесенең татар телен өйрәнүенә, ул телдә сөйләшүенә, әдәбияты белән кызыксынуына соклануын яшермәде.

21 ФЕВРАЛЬ – ХАЛЫКАРА ТУГАН ТЕЛ КӨНЕ

– Татар җырларын тыңлыйсызмы?

– Әйе. Әйтик, «Айфара» төркеменең «Ак каен» җыры ошый. Филүс Каһиров башкаруында татар халык җырларын тыңларга яратам, аеруча «Кара урман» күңелгә якын. Соңгы дүрт ел дәвамында «Татар җыры»на йөрим. «Барс-медиа» ширкәте хуҗалары Гәрәевләр – гаиләбезнең якын дуслары. Алар бик мөһим эш – татар җырларын илебездә яшәүче татарларга гына түгел, чит илдәге татарларга да җиткерү белән шөгыльләнәләр, фестивальдә яңгыраган җырлар аша аларга туган як, туган ил, туган халыкларының күңелләрендәге җылылыкны, үзләренең зур бер милләтнең өлеше булулары тойгысын җиткерәләр дип саныйм.

– Читтә яшәүче милләттәшләребезнең татар телен саклау мәсьәләсенә күпкә игътибарлырак булуы күзәтелә. Сезнеңчә, сәбәп нәрсәдә?

– Мин күп илләрдә укыдым, шул исәптән Америка Кушма Штатларында, Бөекбританиядә озак кына яшәргә туры килде. Бер генә әйберне ассызыклап әйтә алам: читтә туган телдә яңгыраган теләсә нинди җырның, шигырьнең өзеге, сөйләм сине бераз гына булса да туган илеңә, туган нигезеңә якынайта. Шуңа күрә дә туган илләреннән читтә яшәүчеләр туган тел, туган ил, туган халкы белән бәйле төшенчәләргә саграк мөнәсәбәттә. Татарлар, барыбызга да мәгълүм булганча, дөнья буйлап сибелгән милләтләрнең берсе. Президентыбыз Рөстәм Миңнеханов күптән түгел АКШта булды, анда татар диаспорасы белән очрашты һәм алар өчен бу очрашу гаять көтелгән, әһәмиятле вакыйга булып, үзләренең туган ил, халык белән бергә икәнлекләрен тоярга ярдәм иткәндер дип уйлыйм. Алар, җиңелчә инглиз акценты белән булса да, татар телендә сөйләшәләр, аны кадерлиләр, саклыйлар. Россиядән читтә яшәп тә, аның бер өлеше булган татар телен, мәдәни, рухи кыйммәтләрен саклап калулары өчен олы рәхмәт әйтәсе, аларга баш иясе килә.

Мин үземнең өемне, илемне, иң якын кешеләремә яши торган республикамны, Казанымны бик яратам. Бу хиснең тирәнлеген чит илдә озак торганда аеруча тирән тоям, аңлыйм.

Җырлап яшәргә кирәк

Рәис Гобәйдуллинның җырларын **www.shahrikazan.com** сайтыннан тыңлый аласыз.

Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз, диләрме әле? Газета укучыбыз Рәис Гобәйдуллинның да кулыннан килмәгән эше юк: тегә дә, чигә дә, гармунда да уйный, көйләр, шигырьләр дә яза, агачка уеп, төрле сурәтләр төшерә. 75 яшендә булуына карамастан, гөлләр үстерә, спорт белән шөгыльләнә, китаплар бастыра.

Бу гаҗәеп кеше белән «Мәңге яшисе килә» клубында танышкан идем.

– Нәселебез белән гармунчылар. Әти, башкалардан качып, мунчада гармун суза торган булган. Мин дә абыйларым кебек, биш яшемдә үзлектән тальянда уйнарга өйрәндем, – дип искә ала балачак елларын Рәис абый.

Белеме буенча ул – укытучы. Казан мәктәбендә 42 ел укыткан. Укучылары аны әле дә хөрмәт белән, яратып искә алалар. Шартлы рәвештә хөкем ителгәннәр белән тулай торакта тәрбия эшләре дә алып барган. Анда туплаган тәҗрибә укучыларны, үз балаларымны намуслы, тырыш итеп тәрбияләргә ярдәм итте, ди.

– Элек һәр тулай торакта тәрбиячеләр бар иде. Мин шартлы рәвештә хөкем ителгәннәр тулай торагына билгеләндем. Гаҗәп тоелса да, эшемне яратып башкардым. Хөкем ителгәннәр белән 15 ел дәвамында ниләр генә эшләмәдек: спорт белән дә шөгыльләндек, концертлар да куйдык, агачтан төрле сыннар, кул эшләнмәләре ясарга да өйрәндек, – ди Рәис абый.

Тырыш хезмәте өчен, Эчке эшләр министрлыгыннан грамота белән дә бүләкләләр.

Хатыны Мәрьям апа белән ике ул тәрбияләп үстергәннәр. Биш оныклары бар. Тик хатыны гына яшьли китеп барган.

«Мәңге яшисе килә» клубы – күпләр өчен юаныч. Рәис абый да биредә оештырылган чараларда катнашып, тормыш мәшәкатьләрен онытып тора. Флера апа белән дә шунда танышкан. Күптән түгел, картаймыш көндә бер-беребезгә терәк булырбыз, дип, ике ялгыз йөрәк язмышларын уртак итәргә булганнар, никах укытканнар. Олыгайган көндә янәшәңдә киңәшер, серләшер, авыр чакта ярдәм итәр кешең булу бәхеттер ул.

Бүген Рәис Гобәйдуллинның 100дән артык җыры бар. Алар өч китапта тупланган. Соңгы басмасы әле яңа гына табадан төшкән. Җырларның күбесе «Мәңге яшисе килә» клубы оештырган концертларда яңгырый. Ә менә эстрада җырчылары арасыннан да аларны башкаручылар сирәк.

– Ничек инде минем җырны җырлагыз диярге була? Кеше үзе килеп сораса бер хәл, бушлай да бирер идем, мин җырларны акча эшләр өчен язмыйм, – ди автор.

Сүзләрен үзе дә яза, шагыйрьләр Вазыйх Фатыйхов, Фәүзия Солтан, башкалар белән дә эшли. Көйләр язарга үзлектән өйрәнгән. Танылган композитор Әнвәр Бакировтан махсус дәресләр алган, ноталарны үзләштергән.

Ул җырларын башкарган арада, мин тыңлый-тыңлый кул эшләнмәләрен карадым. Менә хатыны белән икесе өчен махсус бертөрле итеп теккән пәлтәләре, апасына атап тегелгән күлмәк. Мутон, кайры туннарга кадәр тегә торган булган укучыбыз. Стенада чалыштырып чиккән картиналары. Бер сурәтне чигәргә ярты еллап вакыт китә икән.

Рәис абый көн саен гимнастика ясый, кышын чаңгыда йөри. Җәен бакчада җиләк-җимеш, яшелчә үстерә. Балкон тулы гөлләр.

– Мин беркайчан да кешедән сорамадым. Булдыра алганча, бөтен нәрсәне үз кулларым белән эшләргә тырыштым. Бу дөньяда һәркем үз тормышын үзе төзи. Үз кәефеңне үзең күтәрергә кирәк. Җырлап яшәгез, җырлау сәламәт булу өчен дә кирәк, – дип киңәшләрен бирде.

Эльвира МОЗАФФАР.

«Соңгы чиккә җиткермәгез»

Татарстан шифаханәләре белән таныштыруыбызны дәвам итәбез. Чираттагы сәяхәтебез Яшел Үзән районында урнашкан «Волга» шифаханәсенә.

Зөлфия ХӘЛИУЛЛИНА

Казаннан чыгып 40 минутлык юл үттекме, юкмы – шифаханәгә барып та җиттек. Яшел Үзән районы республиканың иң матур районнарыннан берсе санала. Бер уйласаң, бу да ял итәргә теләүчеләр өчен бик мөһим, шулай да, статистикадан күренгәнчә, шифаханә сайлаганда, кеше иң элек дәвалау үзлекләренә, аннан соң яшәү шартларына һәм туклануга игътибар итә.

Шифаханә директоры Гамид Гамидов та әлеге фикер белән тулысынча килешә.

– Шифаханәгә барырга ниятләгән көннән, кеше анда баргач ял итәчәкмен, дәваланачакмын дип үз-үзен ышандырып куя, өметләнә. Шуңа күрә аның кәефен бозарга, ышанычын югалтырга бик кечкенә генә сәбәп тә җитә. Мисал өчен, буялмаган ишек, каршы алучының салкын карашы. Бу аңлашыла да, санаулы көнгә килгән кеше, көнен генә түгел, һәр минутын файдалы итеп үткәрергә тели, – ди җитәкче.

Соңгы ел ярым эчендә шифаханәдә зур үзгәрешләр булган. Бу иң элек дәвалау төрләренә кагыла.

– Зур мөмкинлекләргә ия яңа төрле җиһазлар алдык, ванналарның төрләре артты. Туклануны да тамырдан үзгәрттек, азык-төлек алу өчен киткән чыгымнарны арттырдык. Җитештерүчеләр белән турыдан-туры килешү төзеп, бары тик сыйфатлы ризык кына сатып алабыз. Мисал өчен, май һәм сырны – Балтачтан, итне Сабадан китертәбез. Шул ук вакытта путевкаларның бәяләрен арттырмыйча саклап калдык. Без авыл районнарында яшәүче кешеләргә дә йөз тотабыз. Бүгенге көндә бик күп чит илләрдән, Россиянең барлык диярлек төбәкләреннән безгә килеп ял итәләр. Андый төркем өчен дә барлык мөмкинлекләр тудырылган. Шул ук вакытта керемле кешеләрнең дә безгә килеп ял итә алуы бик мөһим, аларны да хөрмәтлисебез килә. Шифаханәне ошатмыйча киткән кеше кире килми. Соңгы бер ел эчендә ял итеп киткән кешеләрнең кабат килүен күзәтәбез, димәк, дөрес юнәлештә барабыз, – ди Гамид Гамидов.

«Волга» шифаханәсенең үзенчәлекләренең берсе – биредә йөрәккә операция ясалган авырулар реабилитация үтә. Күз алдына китерегез, катлаулы операция ясалып, ун көннән соң алар монда киләләр. Бу – зур җаваплылык. Икенче катлаулы төркем – нинди дә булса патологиясе булган йөкле ханымнар. Бала көткән ананың хәле ярты сәгать эчендә бөтенләй башка юнәлеш алырга мөмкин. Гинекологлар биредә тәүлек буе кизү торалар.

Нинди очракта шифаханәгә барырга соң?

– Иң мөһиме: үзегезне соңгы чиккә алып барып җиткермәгез, – ди «Волга» шифаханәсенең баш табибы Кадрия Заһидуллина. – Сәламәтлегеңне кайгыртырга, үз-үзеңне яратырга, организмга ярдәм итеп торырга кирәк. Авырып бөтенләй аяктан егылсаң, үзеңне дә газаплыйсың, якыннарыңа да авыр. Менә шул вакытта инде мәңге бетмәс төсле тоелган эшләр дә бер читкә куела. Теләге булган һәркемнең бүгенге көндә мөмкинлекләре бар дип исәплим. Пенсионерлар өчен дә барлык шифаханәләр әледән-әле ташламалы путевкалар тәкъдим итеп торалар, социаль яклау бүлекләреннән дә алырга була. Ният – эшнең яртысы, диләр. Елына бер тапкыр шифаханәгә барып ял итүне, дәвалануны максат итеп куясың икән, моңа ирешергә була.

Реклама

Лицензия ЛО-16-01-002892 от 26.08.2013 г.

ЛЕЧЕБНЫЕ ВАННЫ:
Жемчужные, РАДОНОВЫЕ, морские, хвойные, бишофитовые, скипидарные, йодобромные, сухие углекислые, нафталан.

ЛЕЧЕБНЫЕ ПРОЦЕДУРЫ:
Озокерит, парафин, физиотерапия аппаратная (в т.ч. ДЭНАС, биоптрон, лазер, электросон магнитотурботрон и др.), грязелечение, аэрофитотерапия, озонотерапия, гирудотерапия, галокамера, спелеокамера, ингаляция, ароматерапия, массаж, терренкур ЛФК, кислородные коктейли, скандинавская ходьба.
В санатории созданы все условия не только для полноценного лечения, но и для комфортного отдыха:
– парикмахерская, косметологический салон, солярий, услуги маникюра, бассейн, сауна, фитнес-зал, фитобар;
– 4-разовое питание (заказное меню).

Необходима консультация специалиста. Имеются противопоказания

КУНАК БҮЛМӘСЕ

«Артур-Марат» дуэты:

«Менә без хәзер көчле!»

Якты, нурлы, халыкчан һәм гади, аңлаешлы алар. Борын чөеп сөйләшү дә, «әллә кемләнү» дә юк. Рәхәтләнеп аралашыр-сөйләшер өчен һәрчак ачык. Татарстанның атказанган артистлары Артур Минһаҗев һәм Марат Галимов «Шәһри Казан» редакциясенә кунакка килгәч, моңа тагын бер тапкыр инандык.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Марат:

– «Артур-Марат» дуэтының беренче чыгышы 2014 елның мартында булды. Ул вакытта мин бик авыр хәлдә идем, ике аягымны да сындырып, бер ел урын өстендә яттым. Бурычка батып беткән идем. Алга таба нишләргә? Сәхнәгә кабат чыгаргамы-юкмы, дип икеләнеп йөргән бер көнне Раил Яхиевич безне Артур белән бергәләп чыгыш ясарга чакырды. Һәм шуннан соң барлык икеләнүләргә нокта куелды.

– Егерме елдан артык иҗатыгызның кыл икегә бүленгән вакыты да менә шушы, димәк?

Марат:

– Шулай дисәк тә була. «Казан егетләре»ндә яшьлегебез узды. Без эстрадага яңалык алып кердек, сәхнәгә биеп чыга идек, заманча аранжировкалар эшләдек. Бүген Элвин Грей эшләгән эшләрне без эстрадага 2001 елда ук алып кердек. Безгә: «Егетләр, сез 15 елга алданрак атлыйсыз», – диләр. Хәзерге «Казан егетләре»н чын «Казан егетләре» дип әйтә алмыйм. Минем фикеремчә, бу төркемнең иң көчле һәм талантлы составы – Артур, Вәли, Азат һәм мин идек. Бер-беребез өчен җан атып, бер йодрык булып эшләдек.

– Марат, тормыш иптәшең Линара – «Кыю кызлар» төркеме солисты. Күптән түгел генә узган «Балалы солянка»да кызыгыз Камиләнең дә чыгышын күрдек. Бу сезнең өчен тәүге чыныгу булдымы? Алга таба гаилә проектлары оештыру планыгыз юкмы?

Марат:

– Моңа кадәр дә балаларым белән сәхнәгә чыкканым бар иде. Беренче никахымнан ике балам бар. Олы кызым Ралинә бик матур җырлый. Сәхнәгә чыкса, үз тамашачысын табар иде дип уйлыйм. Тик ул, әнисе кебек үк, дин юлына басты. Улым футбол белән мавыга. Кечкенә кызым Камиләгә – дүрт яшь. Ә менә планнар кору мәсьәләсендә безнең Артур оста инде! *(Көлешәләр.)*

Артур:

– Әйе, киләчәктә икебезнең дә гаилә проекты эшләү теләге бар. 17 ел бергә гомер иткән иптәшем Луиза Казан дәүләт мәдәният институтында укыта, «Нурлай» вокал ансамблен җитәкли. Үзе дә бик матур җырлый. Улым Данил – Россия хокук академиясе студенты. Кызым Дианага – тугыз яшь. Анысы коеп куйган артист!

– Егетләр, сез нинди эти?

Марат:

– Олы балаларыма мин бик таләпчән, коры эти идем. Әмма яшь барган саен, «йомшара» төштем. Кечкенә кызымны, киресенчә, күбрәк иркәләргә тырышам. Минем үземнең дә эти бик коры кеше. Әни исә үтә дә тыйнак, юмарт.

Артур:

– Мин бик таләпчән. Балаларга ничек әйтәм – шулай булырга тиеш. Ике тапкыр кабатларга яратмыйм.

– Берничә ел сәхнәдә иҗат иткән җырчылар, мәхәббәт, яшьлек, уен-көлке кебек җиңел эчтәлектәге җырларны арткы планга куеп, җитди темаларга игътибар бирә башлаулары турында еш әйтәләр. Сездә дә андый эзләнүләр бар. Соңгы вакытта репертуарыгызда Роберт Миңнуллин сүзләренә язылган бик матур җырлар барлыкка килде.

Марат:

– «Казан егетләре» төркемендә эшләгәндә үк төрле темаларга, стильләргә мөрәҗәгать итә идек. Кайбер артистларның иҗаты бер җыр тирәсендә генә йөзеп йөри. Ә без эзләнәбез. Чынлап та, безнең иҗатка карата Роберт абый уңай фикерләрен, теләкләрен җиткерде. Үзенең берничә шигырен тәкъдим итте. Аннан соң Зөһрә Сәхабиева репертуарындагы «Эзләр идем сине» җырын да бик яратып башкарабыз. Без аның исемен бераз гына үзгәртеп, «Гомер ике килми» дип атадык. Хәзерге вакытта авылларга концертлар белән йөрибез. Әмма халык безне «Артур-Марат» дуэты буларак бик белеп бетерми әле, «Казан егетләре» белән бутыйлар. Әле күптән түгел генә булган бер очрак турында әйтәсе килә. «Артур-Марат» чыгышын күргәннән соң, безне чакырабыз дип уйлап, «Казан егетләре»н дәшкәннәр. Соңыннан безнең урында егетләрне күреп, бик гаҗәпләнгәннәр.

Артур:

– Айлар, еллар узгач, теге яки бу ситуациягә карашлар үзгәрә, вакыйгаларны башкача кабул итә башлыйсың. Бу репертуарда да чагылыш таба. Иҗатыбызга 20 ел булса да, соңгы икеөч елда бик зур үзгәреш кичердек. Хәзер безнең тамашачы белән аралашуыбыз да башка төрле, чөнки эчке дөньябыз үзгәрде. Элек барыбер хис-кичерешләр өстән-өстән генә иде. Ул еллар белән чагыштырсаң, без менә хәзер аякта ныклап басып торабыз. Беләсеңме, кеше белән аралашуыма кадәр үзгәрде. Игътибарлырак була башладым. Авыр сүз әйтеп, аларның хәтерен калдырудан куркам. Элек башым нәрсә уйлый, телем шуны әйтә иде. Җырлар язуга килгәндә, төрле жанрда иҗат итәсе килә. «Үкереп елап» җырлана торган берничә җыр башкарасым килә, әмма аны халык ничек кабул итәр, дип уйлыйм да тукталып калам. Бу бит шулай ук – сәнгать! Әмма, әйтүемчә, аны бөтен кеше дә аңламаска мөмкин.

– Дуэтыгызда эшләр бүленгәнме?

Артур:

– Менә бу эшкә тулысы белән – мин, ә тегесенә Марат җавапплы дип кистереп әйтеп булмый. Мәсәлән, репертуарга җырлар тәкъдим итү башлыча минем өстә. Әмма без аны барыбер бергә хәл итәбез. Җырларны Альберт Зыятдинов белән яздырабыз. Ә Булат исемле егетебез – концерт директоры. Булат кебек кешеләр турында, аның белән разведкага барырга мөмкин, диләр. Ул – һәр нәрсәгә заманча карый торган талантлы, тырыш егет. Андый тугры дусларыбыз булу үзе зур бәхет.

– Артур, син бит әле Вознесение бистәсендә мәдәният йорты мөдире булып та эшлисең. Бу өлкәдәге уңышларың турында да ишетәсе килә.

– Тырышлыгымны, көчемне шушы эшкә салам. 2012 елда копкоры бинада берни дә юк иде. Ике ай берүзем генә эшләдем. Акрынлап танышларымны җәлеп итеп, Яңа ел бәйрәмен уздырдык. Иданнәренә кадәр үзем югангадыр инде, бу мәдәният йорты бик кадерле миңа. Бүген биредә 20 кеше эшли. Аларның һәрберсе үз урынында, һәркайсы – үз эшенең остасы. 19 түгәрәктә 500гә якын бала шөгыльләнә.

– Җырчы гомере күпме дип уйлыйсыз?

Марат:

– Аякларым йөргәнче сәхнәгә чыксам иде, дип телим.

Артур:

– Җырчы һәрвакыт үсештә һәм эзләнүдә булырга тиеш. Юк икән, аның җырчы буларак гомере дә кыскара. Шәхсән үземә килгәндә, 80 яшькә кадәр үземне формада тотып, сәхнәгә чыгып җырлый алсам, бик бәхетле булыр идем.

– Бер әңгәмәгездә сез, Мәскәүгә китәргә хыялланабыз, дигән идегез.

Артур:

– Китәбез, Алла боерса. Сүз, әлбәттә, күченеп киту турында бармый. Әмма якын киләчәктә Мәскәүдә ешрак чыгыш ясый башларбыз дип уйлыйм.

– Егетләр, бер-берегезгә бәяләмә бирегез әле.

Марат:

– Артур – романтик, тормышны бик ярата, һәрвакыт үсештә булырга омтыла, бик талантлы композитор. Әмма шул ук вакытта ул кая, кайчан барырга кирәклеген онытып та җибәрергә мөмкин.

Артур:

– Марат – бик тәгәл кеше, башлаган эшне ахырга кадәр җиткерә, пөхтә. Бик тәмле итеп ашарга пешерә. Йокларга, ял итәргә ярата. Әмма бер начар ягы бар – аңа телефон «җене» кагылган.

Марат:

– Мине әти: «Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз», – дип үстерде. Шуңа күрә өйдәге бөтен эшне дә эшли алам. Әле күптән түгел генә аларга мунча проектлап, салып бирдем. Бик канәгать калды. Гармунда уйныйм. Пешеренергә бик яратам. Артист булмасам, пешекче булган булыр идем.

– Егетләр, тиздән Казан тамашачысына чираттагы концерт программагызны тәкъдим итәсез.

– Әйе, 7 мартта Филармония концертлар залында өченче концертыбыз була. Без «Казан егетләре»ндә бер зур ялгышлык эшләдек – халык көтсә дә, Татарстанда концертлар белән йөрмәдек. Шуңа күрә хәзер бу эшкә зур игътибар бирәсебез килә. Әлеге тамашада да уннан артык яңа җыр башкарачакбыз. Килегез, көтәбез!

Ир канаты ат була

Миңнефаил абый турында язарга дип, Арборга махсус кайттым. Юк, ул ниндидер батырлык эшләгән кеше түгел, моң-зары да юк. Ул – гомере буе атлар фанаты, 63 ел буе аттан аерылмаган. Балтачлыларга гына хас үҗәтлек, тырышлык һәм сабырлык белән, туган авылында яшәгән һәм эшләгән кеше.

Илфак ШИҺАПОВ

Миңнефаил Мостафин 1938 елда туган.

– Тууын шулай туганмын, тик сугыш чоры ятимнәренә пособие була дип, авыл советы секретаре 1940 елгы итеп яздыртты. Шуның белән пенсиягә дә ике ел соңрак чыктым, – ди, елмаеп.

Мине аның атларга булган мәхәббәте кызыксындыра.

– Бишенче сыйныфны тәмамлагач, беренче тапкыр ат җиктем, – ди Миңнефаил абый. – Эшләсәң, ашарга була бит. Шуннан аерылмадым инде. Әле өйдә ат асраудан туктаганга да өч кенә ел.

12 яшеннән ат җигеп колхоз эшендә йөри башлаган ирнең атлар турында сөйләр сүзе күп. Арборда бүген дә «Миңнефаил аты» дигән гыйбарә яши әле. Башта колхозда, аннан мәктәптә ат белән эшләгән Миңнефаилне атсыз күз алдына да китермәгәннәр. Элегрәк бит авылда бөтен авыр эш ат белән башкарылган. Ул Арборда, күрше авылларда яз саен йөзәрләгән бакча сукалап, бәрәңге утыртып, тырмалап чыккан.

– Хәзер бит бакчаны 10-12 сутый гына утырталар. Ә элек 30-40 сутый иде. Атны ашатсаң, чыдый. Көненә, ким дигәндә, өч бакча эшли торган идем. Ай буе йөрелә иде йорттан йортка, – дип искә ала ул.

– Ел саен йөзәрләгән бакча эшкәртү арыта идеме соң?

– Арыткандыр инде. Тик кеше сорап килгәч, ничек каршы киләсең. Мәктәптә 11 укытучы иде. Барысының да бакчасы бар, авылдашлар, күршеләр... Ел да шул бер үк кешеләргә инде.

Атны, эшләр өчен, өйрәтергә кирәк. Монысын да гомер буе эшләгән Миңнефаил абый. Үз атларын гына түгел, колхоз атларын да өйрәткән.

– Төрле хәлләр булды инде, – ди әңгәмәдәшем, үткәннәрне барлап. – Бер иптәш белән икәү ат җиктек тә өйрәтә башладык. Ат, дулап, тегене тимер торбадан тоткан коймага китереп «сылады» – ярты сәгатьләп тора алмыйча ятты. Үземнең андый нәрсәгә эләккәнем булмады.

Миңнефаил абый кәнәфидә утыра. Янында гомерлек тормыш иптәше Рауза апа. Ул иренең һәр сүзен җөпләп, башын чайкап тора. Иренә булган кадер-хөрмәт Рауза апаның йөзенә чыккан. Ул да сүзгә кушылды:



– Бер чак карап торам, ат өйрәтергә баргач, авыл ирләре яшь бер атны тотып торып җиктеләр дә, Миңнефаил арбага менеп утырды. Тегеләр җигеп тә бетерде, үзләре читкә йөгерделәр дә. Барып, Фаилемне арбадан тартып алырдай булдым шунда...

– Өч ел саен алыштыра идем мин атны. Өч ел ашатам, өйрәтәм, җигәм дә яшькә алыштырам. Ниндидер аерым токымлыларга кызыкмадым – үзебезнекеләр якын булды. Бер тапкыр чегәннәрдән алдым алар асрый торган токымлы атны. Анысы белән дә уртак тел таптык. Сбруйларны, арба-чана, башкасын булдырдым инде. Әле бүген дә тимәгән берничә комплект бар. Дуганы үзебез бөгә идек. Урманда имәннән дугалыкны сайлыйсың, аннан зур итеп учак ягып, учак астына көлгә дугалыкны күмәсең дә учакны тагын яндырасың. Аннан иртән бөгәсең, җайга китерәсең инде. Элек бит дуга бөгүчеләр, камыт тегүчеләр, тәгәрмәч ясаучылар аерым иде. Авыл саен диярлек бар иде алар. Хәзер генә бетте, җигәргә ат бар – дуга таба алмыйлар.

Тормыш аңа шактый кыен ашаткан. Әтисе, өйләнгәч, әнисен алып Донбасска шахтага эшкә китә. Сугыш башлангач, аны шуннан ук фронтка алып китәләр. Әнисе кечкенә Фаил белән авылга кайта, ләкин төп йортта боларга урын юк. Авыл буенча йорттан-йортка кунып йөриләр. Бишенче сыйныфтан ат җигеп эшли башлау да шул сәбәпле.

– Бабай вафатыннан соң гына мендек төп нигезгә. Монда йорт яшәрлек түгел иде. Үзебез ияртеп йөреп асрый торган биш кәҗәбез бар иде, шуларны сатып бура алдык, аны йорт итеп күтәрдек. Аннан пристрой ясадык – авылда андый йорт тагын берәү генә иде ул вакытта. Тормышны шулай яңабаштан кордык инде...

Боларны искә төшергәндә, Миңнефаил абый авыр сулый. Рауза апа кулын аның җилкәсенә салган. Борчылма, әтисе, дигән кебек. Моннан 13 ел элек Миңнефаил абый яман шеш авыруыннан ашказанына операция ясата. Тормышы чыннан да куркыныч астында булса да, Рауза апа бала караган кебек тәрбияләгәнгә, аякка баса.

Алар дүрт бала үстергән. Кечкенә чагында бер улларын югалтканнар. Бала хәсрәтенең иң ачы хәсрәт булуы турында сөйләп тору артыктыр. Шуңа Миңнефаил абый тирән көрсенә дә кабат атлар турында сөйли башлый.

– Атны озак асрадым мин. Абзарда ат булмаса, йорт буш кебек иде миңа. Олыгайгач кына туктадым...

– Ә бүген берәрсе ишегалдыңа ат җитәкләп кереп, мә, асра дисә, нишләр идең?

– Асрар идем, әлбәттә. Әле кызыгам, алыйкмы әллә дим. Атның бит җанын аңларга кирәк. Бездәге атларның бигрәк тә. Ашатсаң, карасаң, аңласаң, алар белән тау күчерергә була. Ашаган ат бер тонна йөкне җиңел тарта. Күбрәген дә тартыр иде – арба чыдамый. Караган, кайгырткан хуҗасын ат ташламый. Кеше акыллары бар бит аларда...

Бүген өйләрендә асрамаса да, әле дә колхоздан алып булса да җиккәләп тора үзе. Әйтик, бу якларда «Әрәпә» дип аталган Сабантуйга сөлге җыю бәйрәменә. Җигүен дә болай гына җикми. Миңнефаилнең атлары һәрвакыт башкаларда булмаганча чуклар, шөлдерекләр белән бизәлеп ялт итеп торалар. Шуңа күрә «Әрәпә»гә чыгучы бала-чага Миңнефаил бабай атына утырырга кызыга.

– Сагынасыңмы атларны, Миңнефаил абый?

– И-и-и, сагынмаган кая?! Төшләремә керә ат җигеп чыгып киткәннәрем...

ПОЧТАДАН

Хәммәтъяр сабагы

Мин атлар яратам. Колхоз атларын. Әти ел әйләнәсендә колхоз эшендә: җир сөрә, иген ура, суктыра, кышын татар, чуаш авылларыннан тула җыеп кайта. Ул пар ат җигеп Нурлат станциясенә иген ташыганда, мин болында атлар көтәм, ат җигеп печән, салам ташыйм.

Авылыбызда дүрт бригада, ә атлар фермасы бер генә. Таң беленүгә, фермага ат алырга киләләр. Мин дә торып шунда чабам. Озак йокласам, эшкә яраксыз ат калыр дип куркам.

Бүген төнге көтүдән атлар кайтмаган да әле. Ат алырга килгән берсе, җыелышып, тузга язмаганны сөйләп утыра. Имеш, Тинай байның сеңлесе Мәгълүмә Ташкентта прокурор булган, ди. Ул безнең авыл мөәзиненең Әдибен төрмәдән йолып калган. Әллә булмаганны сөйлиләр шунда. Моны белүче юк. Аның каравы, Әдипне яхшы беләләр. Ул әүвәлге елларда, ялтыравык офицер погоннары тагып, авылыбызга еш кайтып йөрде. Соңгы кайтуында салым «недоимка»сын түләмисең дип әнисен мәсхәрәләп сүккән салым инспекторын кыйнаганын да бөтен авыл кешесе белә. Кыйнавы ярады анысы, бик азган иде ул инспектор. Шуннан соңгы кайтуында Әдип безнең мәктәп директорына өйләнеп, аны үзе белән алып китте.

«Атлар кайта», – дигән тавыш ишетелде. Ферма йортына йөздән артык ат кереп тулды. Таен ияртеп, Кубанка да кайтып керде. Алдагы еллардагы кебек, урманга качарга өлгермәгән әле ул. Җәй көне эш белән кинәндерми: тибәргә, тешләргә генә оста. Аны җиксә, Әтикай Гасыймы гына җигә ала. Гасыйм үзе дә әле хәзер генә килеп җитте. Ул арьяк урамындагы өйдә ялгызы гына яши. Нигә аңа Әтикай кушаматы такканнардыр? Әтисен сугышка озатканда яңа тәпи йөри башлаган малайның авызыннан чыккан беренче сүзе булганмы ул? Юктыр. Имеш, Морасадагы урман каравылчысы Нургаяз Гасыймнар күршесендәге Фәридә апасының хәлен белешергә килгәч, авыл урамында бүре баласы төслө әүмәкләшеп уйнаган ике малайны күреп, исемнәрен сораган. Бусы – Гасыйм, монысы – Касыйм, дигән күршеләр. Нургаяз Гасыйм исемлесен үзенә уллыкка алып китәргә булган, ләкин ялгышып, Касыймны алган. Усал телле авыл кешеләре Гасыймны, бәхетсез булганга, «Әтикай», – дип үчекли башлаганнар. Барыбер аптырый торганнардан булмады ул, әнә теләсә кайсы атны тотып утка керә ала. Аның йөгәне дә ялтыравыклы каймалар белән шулхәтле матур итеп бизәлгән.

Үз атларыбызны табып, йөгән кидерә башлаганчы, Гасыйм бүген дә атына атланып чабып китте. Без, әти-әнинең җылы кочагында үскән малайлар, Гасыйм кебек ут борчасы була алмыйбыз инде.

Минем таркаурак булып үсүемне әтидән кала башкалар да белә. Бер тапкыр Маңгир җизни мине йөкче малай итеп район үзәгендәге Хәммәтъярларга җибәрде. Хәммәтъяр үзе читкә китәргә җыена икән. Йорттагы иске-москыны җизниләргә алып кайтырга кирәк. Кайбер иске чүкечләр, күмер белән җылытыла торган үтүкне санамаганда, кирәкле нәрсә күрмәдем мин анда.

Ат ял итеп өлгерде инде. Аны җигә башладылар. Шунда Хәммәтъяр янгын сүндерүчеләр өчен әзерләнгән, кара төскә буялган тәртәләр тартып чыгарды. Имеш, әрәм булмасын. Алыштырырга риза булдым. Тәртәләрнең озын икәнлегенә генә игътибар иттем.

Йөк авыр булса да, ат елга буена бик тиз барып җитте. Аның арт аяклары белән чана табаны арасында ярты метр буш урын калган булуына һаман игътибар итмим әле мин. Көн уртасында кояш карны да эретте. Чана табаны бата башлады. Ат йөз метр барган саен туктый. Аны чыбыркылау да файдасыз хәзер, тәмам арыды. Мин дә чанага утырмыйм инде. Атка капчыктагы саламны да биреп карыйм. Аз гына ашый да әлсерәп ял итә. Инде нишләргә? Болай булса, төнгә калам. Бара торгач урман турысына җиттек. Еракта бер атлы күренде. Килеп җиткәч: «Тәртәң озын, төпкә җик», – диде дә үз юлы белән китеп барды.

Шунда гына эшнең нәрсәдә икәнен аңлап алдым. Хәммәтъяр мине сынарга булган. Ул, янгын сүндерүчеләрне өйрәтә торган озын, калын тәртәне миңа тагып, төп башына утырткан.

Камышны бушатып, атны төпкә җиктем. Кузгалып китүгә үк, ат чабарга тотынды. Шул кузгалу белән, авылга бик тиз барып җиттек. Шулай Хәммәтъяр миңа гомердә онытылмаслык сабак бирде.

Рәис ИДРИСОВ,
Казан.

«Мин сихерче түгел»

Рәсилә Кәлимуллина – күрәзәче. Аның турында язарга бер укталган идем, ничектер барып чыкмады. «Үзеңдә шундый гайре табигый сәләт булу куркытмыймы? Бу халәтең өстәмә борчулар тудыра торгандыр? Гадәттә, күрәзәчелекне шайтан коткысы дип аңлаталар, бу чыннан да шулаймы? Әлеге сәләт каян килә?» Рәсиләгә шул сорауларны бирмәкче идем. Ниһаять, очраштык.

Расиха ФӘИЗОВА

«СӘЛӘТЕМ – НӘСЕЛДӘН»

– Бу сәләт нәселдән килә, –диде Рәсилә. – Әнинең туганы да таш сала торган булган. Ә әни үзенә бер психолог иде, 98 яшендә гүр иясе булды. Гомумән, әтием Насретдин, әнием Минсафа искитмәле кешеләр иде. Әниемнән таныш-белеш төшлек салдырыр иде. Ул үлгәч, мин дә төш күрдем: «Шундый әйбәт итеп саубуллаштык», – диде. Бу аның риза булып китүе иде... Нәрсәгә куркырга соң? Киресенчә, кешеләргә ярдәм итә алуыма сөенәм генә. Мондый сәләтнең шайтаннан бирелүенә ышанмыйм. Чөнки ак көчләр белән генә эш итәм. Кемнәрнеңдер арасын бозмыйм, сихер ясамыйм... Мин күрәм...

Кечкенәдән табиб буласы килгән Рәсиләнең. Авыл фермасы янында (Азнакай районының Урманай авылы) мал табиблары ташлаган шприцларны алып кайтып, юып, шулар белән врачлы уйнаган чаклары әле булса онытасы юк. Каз бәпкәсе су буеннан тәпиен сындырып кайткач та, 3-4нче класс баласының үз билгеге белән аның аягына шин салып йөрүе дә үзе бер тамаша була карап торган кешегә. Эт-песиләргә ул-бу була калса да, ярдәменнән ташламый Рәсилә. Үскәч, табиб булып, кешеләргә дә шулай ярдәм итә алсаң иде дип хыяллана. Унынчыны тәмамлагач, сырхауханәгә санитарка булып урнашуы да шул фәрештәләргә тиң ак халатлы табибларга якынаясы килүдән. Пенициллин аллергия биреп җәфаламаса, ул анда күпмегә тоткарланган булыр иде икән – билгесез. Шулай да өметен өзми кыз: Казанга лаборантлыкка укырга китә. Тик укып кайтуга кияүгә чыга да, авылда шактый гына яшәргә туры килә. Аннан Азнакайга, соңрак Казанга күченәләр. Хезмәт юлы да башка юнәлеш ала. 23 ел буе балалар бакчасында башта няня, аннан тәрбияче булып эшли. Эшеннән аерылмый гына педагогика көллиятен тәмамлый. Балачак хыялы белән бик җиңел генә саубуллашкан бу дияргә ашыкмыйк әле. Бераз алга китеп булса да шуны әйтергә кирәк: хәзер аны белгән табиблар вакыт-вакыт теге яки бу авыру уңаеннан үзләре ярдәм сорап килә.

КҮРӘЗӘЧЕ

Кеше күрмәгәнне күрүчеләрне күрәзәче, диләр. Рәсиләдә дә бу сәләт үзен яшьли сиздерә башлый. Җиденчедә укыганда классташ малаен, син фәлән көн буе мотоциклга утырма әле, дип кисәтә. Билгеләнгән срок тәмамланырга бер көн кала, түзми бит тегесе – Көчле Бүләккә кайтканда, мотоциклдан егылып аягын сындыра. Бер танышын «Ирең ай буе рульгә утырмасын», – дип кисәтү аннан соң да була. Адәм баласы тәкатьсез бит – бер көн кала утыра – кеше таптата.

– Миңа төш тә бик рас керә, – ди Рәсилә. – Бервакыт төшкә бер тапкыр да күрмәгән әбием – әнинең әнисе керде. Аермачык. Әнигә төш сөйлим: әбине төштә күрдем, бите шадра икән, дим... Әни барысын раслап барды... Югыйсә, бу хакта бер тапкыр да сөйләшкәнебез дә булмаган иде... Моннан элек бер танышым шалтырата: иремнең кан басымы төшми, ди. Берүк, юлга чыкмасын – үлем күрәм, дидем. Чыннан да, аның кан басымы гына да түгел иде. Тулы диагнозын әйтеп бирдем. Ул шул көнне үк реанимациягә эләкте.

Ике улы да мәктәп яшеннән үк футбол уйный. Кайвакыт алар да телефоннан: «Теге җир «шырт» итте, бу җир шәп кенә бәрелде, сынмаганмы?» – дип шалтырата икән.

– Бервакыт болар команда белән футбол ярышына Азов диңгезе буена киттеләр. Төн уртасы җитте, күңел тыныч түгел. Ут дигән хәбәр тынгы бирми. Ул вакытта кәрәзле телефон юк заман әле. Күңелемнән генә улым белән сөйләшәм: берүк, йоклый күрмә, ут, дим. Ун көн дигәндә кайттылар. «Барганда, бөтенесе йоклый, мин генә йоклый алмыйм, тәрәзәдән карасам, автобус астыннан ниндидер ут, очкыннар чыга. Автобуска чак кына ут капмый калды. Туктадык», – ди бу...

Югалган кешеләрне дә вакыт-вакыт эзләтәләр Рәсиләдән. Эзләп-эзләп тә тапмагач, полиция вәкилләре үзләре үк баш иеп килгән чаклар була икән.

Бервакыт шулай Екатеринбургта укучы улын озатырга йөргәндә, бер егет югалды, ярдәм ит, дип килеләр. Биш көн таба алмыйлар икән. Буага су керергә барганнар, иптәшләре кайткан, бу юк, ди. Водолазлар да эзләп караган.

– Мине дә шул буага алып бардылар. Җинаять эшләре бүлеге җитәкчесе дә, егетнең әнисе дә шунда. Бөтен кеше аптыраşта. «Исәнме ул? Кайда?» – дип сорыйлар. «Исән түгел. Шушында, буа астындагы торбага кысылган, – дим. Юлның икенче ягындагы коеның вентилен сүтеп, торбага һава кертергә кирәк, 10 минуттан мәет чыгачак», – дидем.

ШУЛАЙ БУЛА ДА...

Моннан соң Уразайда бер егет югала. Урман буенда ул йөргән җирләрдә йөриләр. Рәсилә: «Бүген таба алмыйбыз», – дигәндә генә, кулына бер күбәләк килеп куна. Бу инде ишарә: үлгән егетнең җаны. «Әгәр дә мин дөрес эзлим икән, син минем янымнан китмә», – дип, күбәләк белән эчтән генә сөйләшә Рәсилә. Беркадәр баргач, ниндидер хәбәр биреп, күбәләк селкенеп куя. Барысы да машинадан төшәләр. «Иртәгә шушында килеп эзләгез, табасыз», – ди ул, юлдашларына. Чыннан да, икенче көнне егетнең мәете табыла.

– Бер елны мәктәп яшендәге кыз бала югалды. «Исәнме?» – дип килделәр. Бала исән, өч көннән табыла, дидем. Караңгыда кайтканда, өсте ачык калдырылган коега төшкән була кыз. Әле менә тагын Әлмәттән шалтыраттылар: бер хатынны эзлиләр. Өенә күптән кайтмаган икән. Ул инде исән түгел. Карлар ачылуга шалтыратырсыз, урынын өйрәтермен, дидем...

Мал-туар югалу очраклары да гел булып тора. Берсендә үгезебез югалды дип, Башкортстаннан шалтыраталар. «Йорт саен кереп эзләгез, табыла», – ди ул аларга. Чыннан да, йорт саен йөри башлагач, карак исеме күтәрәсе килмәгән бәндә малны чыгарып җибәрергә мәҗбүр була. Кайтачак, табылачак, исән... Мондый юрауларның рас килүе әйткән кешегә ышанычны бер арттырса, эзләүчегә өметен җуймаска бер сәбәп булып тора шул.

Теге яки бу чирдән дәва таба алмаганнарның да өметен кисми Рәсилә. Күп кеше авыруының сәбәбен тапмый торып, төшенкелеккә бирелә башлый, дигән фикердә ул. Кемнәр генә килмәгән инде аңа. Әле күптән түгел Сөләйдән берәү: «Авыруымны таба алмыйлар, йөрмәгән хастаханә калмады. Онкологиягә дә күп йөрттеләр инде», – дип килгән.

– Теле җәрәхәт кенә моның. Бер нәрсә ярдәм итми, ди. Борыныңа тамыза торган әйберне салмыйча тор, төзәләчәк, дип озатып җибәрдем. Аллергия иде аңарда. Чыннан да, бер атна дигәндә, бер әйбер дә калмады. Тагын берәү килде. «Онык аңын югалтып, реанимациядә ята. Күзен дә ача алмый. Ярдәм итә алмыйлар», – ди. Ничек булса да, аннан алып чыгыгыз да тешен дәвалатыгыз, үлеклләгән, дидем. Тешен алдылар – бала терелеп китте. Мондый тарихлар миндә бихисап, яза барсаң, үзе бер китаплык булыр иде инде, – ди Рәсилә ханым.

НАРКОТИКЛАРГА – ЮК!

Дәваланмыйча ярамый

Бүгенге көндә 9368 кеше табиб-наркологларда исәптә тора. Аларның 77 проценты – 20-39, 22 проценты – 40-59 яшьлекләр. Социаль статусларына килгәндә, 68 проценты эшсез санала, 31 процентының эше бар, калган 1 процентын югары уку йортларында, училищеларда укучылар алып тора.

Журналистлар белән очрашуда Республика клиник наркология диспансеры баш табибы урынбасары Резеда Хаева шундый саннар китерде.

– Наркотикка бәйлеләргә ярдәм күрсәтү өч этаптан тора. Беренче этап – наркотик кулланучыларны ачыклау һәм аларны дәваланырга күндерү. Әлеге эш дини конфессияләр, «Тимур Исламов фонды», «Новый век», «Профилактика һәм инициатива» кебек иҗтимагый оешмалар белән алып барыла. Ни өчен дигәндә, наркотик кулланучылар беркайчан да үзләре ярдәм сорап килми. Алар «ябык» төркем. Икенче этап – наркотикка бәйлеләрне дәвалау һәм медик-социаль тернәкләндерү. Алар дәүләт наркология учреждениеләрендә һәм тернәкләндерү үзәкләрендә дәвалана. Соңгы этап – социаль тернәкләндерү. Кайбер пациентлар дарулар эчәм дә дәваланам дип уйлый. Наркотикка бәйлелекне алай гына җиңеп булмый. Дарулар белән генә дәвалану җитми, психологик ярдәм дә кирәк. Кеше җәмгыять, гаилә әгъзалары белән аралашырга кабат өйрәнә. Бу этапта безнең бурыч – аны тулы канлы тормышка кайтару. Шул рәвешле республикада наркотикка бәйле булганнарга ярдәм итүнең күп этаплы комплекслы системасы бар. Моның өчен кирәкле инфраструктура булдырылган, белгечләр әзерләнгән. Наркомания һәм алкоголизмның таралуын кисәтә, яшь буынны сәламәт яшәү рәвешенә чакыра торган профилактик чараларның да роле зур, – дип сөйләде ул.

Әңгәмә барышында Резеда Хаева район хастаханәләрендә психиатр-нарколог кабинетлары булуын, анда наркотик кулланучы яшүсмерләргә ярдәм күрсәтелүен әйтеп узды. Республика буенча исәпләгәндә, учетта балигъ булмаган шундый 82 бала тора. Башка еллар белән чагыштырганда, аларның саны кими бара. Тик шулай да ата-аналарны спикер игътибарлы булырга чакырды.

– Наркотик куллана башлаган баланың укуы түбән тәгәри, ул дәресләргә йөрмәскә, өйгә соң кайтырга мөмкин. Шикле яңа дуслар табыла. Проблеманы өйдә генә хәл итү дөрес түгел. Тиз арада белгечләргә мөрәҗәгать итәргә кирәк. **272-33-13** ышаныч телефоны тәүлек буе эшли, – дип кисәтә нарколог.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА.

Бер мәхәббәт тарихы

«Яланаяклы кыз» сериалына – 10 ел

«ТНВ» каналы төшергән «Яланаяклы кыз» фильмына ун ел булган икән. Раушан Шәриф сценариесе буенча Нурания Җамали төшергән әлеге сериалны күпләр яратып карады. Анда уйнаган актерлар бүген ни белән мәшгуль? «ШК»хәбәрчесе сериал геройларын эзләп табып, хәл-әхвәлләрен белеште.

Нурания ҖАМАЛИ,
куючы режиссер:

– Шушы көннәрдә генә Россия авторлык җәмгыяте фильмнардагы музыкаль әсәрләрнең авторларын барларга кушты да, «Яланаяклы кыз»ны башыннан азагына кадәр карап чыгарга туры килде. Гадәттә, үзем төшергән фильмнарны карамыйм мин. Ә моны карап чыккач, шулкадәр рәхәт булды. Ничек эшләп чыктым икән, бу кадәр эшне ничек булдырдым икән, дип, үземне кызганып та, шул ук вакытта мактап та куйдым. Әлбәттә, фильм төшерү – авыр эш. Әмма чип-чиста кассетага яңа төшерелгән фильмны яздыргач, шулкадәр куанасың, ләззәтләнәсең.

«Яланаяклы кыз»га килгәндә, ул җәйнең иң матур вакытында искиткеч табигатьле Кошман авылында төшерелде. Авыл халкының ярдәмчеллегенә мин әле дә рәхмәтлемен. Алар безнең эшне күпкә җиңеләйтте.

Төп рольне Асылъяр уйнады. Ул бит актер түгел, ә эшен шулкадәр оста башкарып чыкты! Аны тагын берәр фильмда күрәм. Миңа калса, үзенең яшенә туры килгән рольне бирсәләр, ул аны Дилбәр роленә караганда да ныграк бирелеп, күпкә тәҗрибәлерәк уйнар иде.

Тамашачыга рәхмәт: фильмны күтәреп алдылар, яраттылар. Кассетадан соң без аны диска да чыгардык. Берсендә дисклар сатучы танышымны очраттым, «Авылга әниләргә «Яланаяклы кыз»ны алып кайттым. Авыл әбиләре атна буе кичен җыелып, чәй эчә-эчә, фильмны кат-кат караганнар», – ди.

Әйе, күңелгә хуш килә торган әйбер булды ул. Аннан соң шактый күп фильмнар төшерелсә дә, «Яланаяклы кыз» сагындыра.

Дилбәр – АСЫЛЪЯР:

– «Яланаяклы кыз»да төшү – иҗади юлымдагы иң зур вакыйга. Фильмны бик яратып эшләдек. Ә рольгә килгәндә, ул миңа җиңел бирелде. Тормышта нинди – анда да шундый булып калдым. Ни сәбәпледер, «Яланаяклы кыз»га кадәр дә, аннан соң да башка бер фильмда да төшәргә тәкъдим итмәделәр. Әгәр тәкъдим итсәләр, мөгаен, төшәр идем. Тик башта фильмның сценариесе, үземнең булачак ролем белән танышыр идем, әлбәттә. Әгәр үземдә әлеге рольне башкарып чыгарлык көч тойсам, ике куллап алыныр идем.

Мин бүгенге көндә декрет ялында. Ике сабыем бар. Узган елның 6 маенда Әмир улымның сеңелкәше туды. Чын хатын-кыз бәхетен тоеп яшим, Аллага шөкер.

Самат – Руслан САФИН:

– Фильмга очраклы рәвештә килеп эләктем. Тренировкадан соң дусларым кастингка алып барды. Минем рольгә теләүчеләрнең саны – 300 кеше! Кушылган биремне эшләдем дә өйгә кайтып киттем. Моны ничектер җитди кабул итмәдем. Җиңеп чыгуыма да ышанмадым, чөнки көндәшләрем – талантлы актерлар һәм җырчылар. Ә мин сәнгатькә берничек тә бәйле кеше түгел. Бер атнадан шалтыраттылар, мине сайлаганнар икән. Уйнавы авыр булды дип әйтә алмыйм, чөнки сериалда да үзем булып калдым.

Белемем буенча мин – инженер. Ике югары белемем бар. Кайчандыр музыка мәктәбен дә тәмамладым. Фильмда гармунны белеп тартам, килештереп кенә уйнамыйм. Баяннан тыш, гитара һәм барабанда да уйный беләм.

Бүгенге көндә пыяла әйберләр җитештерү белән шөгыльләнәм. Өйләндем, ике улым бар – Ранель һәм Рамир. Нарат урманында йорт салдым, гаиләм белән шунда рәхәтләнеп яшибез.

Ун ел үтсә дә, мине әле дә урамда Самат буларак таныйлар. Югыйсә, хәзер тышкы кыяфәтем бөтенләй башка. Элек автографлар сорап йөдәтеп бетерәләр иде. Бу – популярлык бизнесымда зур ярдәм. Танычгач, булачак клиентлар миңа ышана, шул рәвешле уртак тел табу күпкә җиңелрәк.

Алсу – Ләйсән СӨНӘГАТОВА:

– Алсу роленә туры килерлек өч кызны сайлап алганнар иде. Рольне миңа биргәч, бик сөендем.

Тискәре рольләрнең берсен уйнарга туры килде. Әлбәттә, тамашачы мине яратмады. Миңа, Ләйсән Мәхмүтовага юлланган хатлар редакциягә бик күп килгән. Аны бит кешедә нәфрәт тудырырлык итеп уйнарга да кирәк. Әмма вакыт кешенең фикерен үзгәртә, хәзер, киресенчә, «Афәрин, «Яланаяклы кыз»да шәп уйнаган идең», – диләр.

Әлбәттә, роль белән холкым арасында бер охшашлык та юк. Мин гомеремдә дә кеше арасына кермәдем һәм кермәячәкмен, башканың сөйгәнен дә тартып алмаячакмын. Гайбәт тә сөйләп йөри торганнардан түгелмен. Усаллыгым бәлки туры киләдер. Тормышта мин бераз усал, әмма яхшы усал.

Бүгенге көндә Казан филармониясендә эшлим. Ике кыз үстерәбез. Ралинага – 9, ә Эльвинабызга 3,5 яшь.

Илнур – Элнар ЯРКӘЕВ:

– «Яланаяклы кыз» – Татарстан телевидениесенең иң уңышлы фильмнарының берсе, дип әйтер идем. Халыкчанлыгы, гадилеге, геройларның безнең арадан булуы аны аеруча популяр итте. Әлеге фильмны булдыруда үз көчен салган һәркемгә рәхмәт белдерәсем килә.

Илнур – кызыклы роль. Урыслар әйтмешли, «Есть над чем поработать». Чынлыкта ул начар кеше түгел, җавапсыз мәхәббәт кенә аны начар итеп күрсәтә.

Фильмда төшкәнче, спектакльдә уйнаганым бар иде. Әмма фильм белән спектакль – икесе ике әйбер. Экранда бөтен фальш һәм ялган күренә. Монда күбрәк үзең булып уйнарга кирәк. Роль авыр бирелде. Дубльләр ясаганда, һәрбер җөмләне берничә тапкыр кабатларга туры килә иде. Ул ун тапкыр яздырылса да, син аны бертөсле кабатлап уйнарга тиеш. Илнур образы чын табигатемнән аерыла, мин андый түгел. Сериал чыкканнан соң, күпләр: «Ах, син шундый усал икән», – диде. Йә, киресенчә: «Син «Яланаяклы кыз»дагы Илнур түгелме? Тормышта син бөтенләй башка икән. Сине явыз, начар буларак белә идек», – диделәр. Димәк, тамашачыны ышандырганмын.

Ун ел да узган икән. Ә күңелебез белән без һаман да шул яшь егетләр һәм кызлар. Мин инде бу вакыт эчендә өйләнергә өлгердем. Хәләлем белән улыбызны тәрбиялибез. Аңа 7 яшь, беренче сыйныфта укый. Алла боерса, бу көннәрдә икенче сабыебыз туарга тиеш.

Гөлҗамал – Флера ХӘМИТОВА:

– Академия театрында 24 ел эшләү дәверендә бер дә өлкән яшьтәге рольне уйнарга туры килмәде. Шуңа күрә Гөлҗамалга мин бөтенләй әзер түгел идем, башта каршы да килдем. Әмма уйный башлагач, образга тиз кереп киттем.

Дилбәрнең: «Дәү әни!» – диюләре йөрәгемә кадәр үтеп керә иде. Ул шулкадәр җиңел һәм рәхимле итеп эндәшә. «Дәү әни» дигән сүзгә нык күнектем, съемкалардан соң берәр җирдә ул сүзне ишетсәм, миңа эндәшәләр бугай, дип, кат-кат борылып карый идем.

Сериалның шәп килеп чыгуының бер сере – команданың үзара дус булуы. Съемкаларда көлә-көлә, рәхәтләнеп яшәдек. Яшьләрне гел хәтергә төшереп торам. Әле дә булса сагынып искә алам.

Бүгенге көндә укыту эше белән мәшгульмен. Мәдәният институты һәм музыка көллияте шәкертләрен сәхнә теле һәм актерлык осталыгы серләренә төшендерәм. Укучыларым өчен өзелеп яшим. Телевизордан чыгышларын карыйм, алар катнашкан концертларга йөрим. Укытучы буларак, кимчелекләрен күрәм, аннары хаталар өстендә эшлибез.

Айбулат – Әсхәт ХИСМӘТОВ:

– Әлбәттә, тамашачы Айбулатны җәлләде. «Шундый җебек ир-ат буламыни», – дип сүктеләр дә. Нишләтәсең, әтисез үскән ул, шуңа да йомшак холыклы. Әнисе: «Әтиең әлеккәдә сиңа», – дип, берничә кат әйтеп куя бит. Өстәвенә, хатыны да иртә үлеп киткән. Ә ашарга да пешермәгән икенче хатыны бер кочаклап үбә дә, әлбәттә, ир эреп китә. Ир-атка күп кирәкмени инде?!

Кәефне иң төшергәне – фильмның сценариесе үзгәрүе. Төшерелгән шундый шәп кадрлар калды. Элекке сценарий буенча булган булса, халыкны бөтенләй елата торган булачак иде ул.

Кошман авылы халкы турында җылы хатирәләр күңел түрендә әле дә саклана. Авыл советы җитәкчесе шундый шәп кеше иде. Алар безне шулкадәр матур каршы алды. Фильм төшерү өчен барлык уңайлыкларны тудырдылар. Айбулат механизатор булып эшли бит инде, аңа да әле тракторын, әле комбайнын әзерлиләр. Көненә берничә тапкыр тәмле ризыклар пешереп, ашханәдә ашаталар. Бернинди проблемабыз булмады: бирелеп эшлә генә!

Әминә – Ләйсән МӘХМҮТОВА:

– Ул елларны гел сагынып искә алам, чөнки яшьлекнең матур мизгелләренең берсе. Фильмда катнашырга режиссерыбыз Нурания апа чакырды. Мин кастингтан узып тормадым. Әлеге рольне Раушания Юкачева уйнарга тиеш иде, әмма гастрольләргә чыгу сәбәпле, катнаша алмады. Ә нинди җитди кастинг булганын ишетеп беләм. Мин соңрак килдем.

Минем рольгә килгәндә, әлбәттә, тырышып эшләргә туры килде. Үземне җәллим дә әле: мине бит иремнең кызы Дилбәр яратмады. Әлбәттә, якты йөз белән каршы алмагач, мин дә шундук холкымны күрсәтә башладым. Әмма, ни кызганыч, Әминәләр бүгенге тормышта бик күп. Тик мәхәббәтсез бәхетле булып булмый, анысы көн кебек ачык.

Әминә образы белән охшаш якларым да бар. Әгәр дә минем җенемне котыртсалар, «кыздырсалар», җен пәриләрем шундук чыга һәм бик каты әйтеп куюым бар. Әмма мин беркайчан да кеше язмышы белән уйный алмаячакмын. Кешене яратмыйм икән, байлыгына кызыгып, аның белән булу уе бөтенләй дә юк. Кешеләрне кыерсытып яшәргә дә намусым рөхсәт итми.

Әминәне җиренә җиткереп, рәхәтләнеп уйнадым. Фильм чыкканнан соң, ике-өч ел мине хатын-кыз тамашачы күрә алмады, ә ир-атларга ошый идем. Рольнең шул күңелсез ягы бар.

Зоя СОЛОШИНА.

Безнең Әти – мировой!

Сез Сәяф Хәсән улы Хәсәновның кем икәнен беләсезме?! Белмәсәгез, хәзер әйтәм: Мамадыш районының Урта Кирмән авылында тугызынчы дистәсен ваклап, хатыны Гөлфәридә белән тыныч кына гомер кичереп ятучы ир, өч кызының сөекле әтисе, ике киявенең һәм биш оныкның яраткан алтын бабасы иде ул моңарчы. «Шәһри Казан» газетасының иң яхшы әтине барлаганын ишеткәч, аның кандидатурасын бергәләп якларга булдык әле менә, чөнки безнең ӘТИ – мировой!

Гомере буе Мамадыш районының Киров исемендәге колхозында алдынгы тракторчы булды Сәяф Хәсәнов. «Хезмәт Кызыл Байрагы», «Өченче дәрәҗә Хезмәт Даны» орденнары, «Хезмәт ветераны» медале, тагын бик күпсанлы күкрәк билгеләре бар. «Социалистик ярыш алдынгысы» – 1нче урын» дип кызыл комачка язылган тасмаларыннан, Мактау кәгазьләреннән, дистәләгән матур значокларыннан әни өй түрендә кызыл почмак ясады. Мәктәптә укыганда, Мамадышка баргач, райком каршындагы Мактау тактасында әтинең олы портретын күреп тә сокланып, горурланып басып торганымны хәтерлим. Әни безне аның якты образы белән тәрбияләп үстерде, артыгын шаяра башласак: «Әтиегезгә әйтәм!» – ди торган иде. Ә минем әтине би-и-и-и-ик күрәсем килә. Беркөнне әнидән иртәрәк уятып, әтине күрсәтүен сораган идем, уятмаган булды. Сыңар күземне ачтым да мыштым гына тыңлап ятам боларның өстәл артында сөйләшкәнен: «Сәяф, җәй узып бара, мунча миче төтенне кирегә бәрә, кышлык печән әзерләнмәгән һаман, шул трактор сәнәгеңә каптырып бер колач печән эләктереп кайтсаң ни була, бурлык түгел, эшеңә көнлек нәтиҗә генә бит ул. Сыерны үгезгә аптөшәргә кирәк, ни уйлыйсың син, ә-ә-ә-ә? Такыр басу өрәге; колхоз, дип яралган коммунист, орденнарыңның бер ягы минеке, белеп тор, яме...» Әти берни эндәшмәде, таң белән тирә-юньне яңгыратып, тракторын кабызды да тагын китеп барды инде яраткан эшенә. Ә мин әнинең әтигә биргән бу сабагын – «серне» гомер буе үзем генә белдем түлке, менә хәзер искә төште дә сезгә генә әйтәм.

Беркөнне шулай әтинең теге матур значокларын сораган идем, берсе чыкмады. Кая киткәнен сорадым кәнишнә. «Хезмәттәшемнең (исемен әйтмим инде, ярар) улы солдаттан кайткан. Гимнастеркасының түше буш. Егет кешегә алай килешми. Авылдашлар каршында яхшы түгел. Җәлләдем дә үзе теләгәнен сайлап алырга куштым, тагып йөрсен рәхәтләнеп!» – диде. Һмм, мин дә нәкъ шунысына кызыгып йөри идем.

Ә бер тапкыр телевизордан бергәләп сугыш, балалар йорты турында кино карап утырганда, әтинең күзләрендә яшь күреп шаккаттым: ничек елый инде, ул бит, ул бит – безнең ӘТИ?! Үсә төшеп, аның биографиясен белгәч кенә эшнең нәрсәдә икәнен аңладым. Сугыш вакытында әтисе яу кырында хәбәрсез югалган, әнисе көтү көткәндә салкын инеш суына төшкән бәрән артыннан сикереп, суык тидереп үлеп киткән. Тома ятим калган алты балалы гаиләдәге ике сабыйны Кукмара районының Түбән Арбаш балалар йортына илтеп биргәннәр. Мир белән үстергәннәр кечкенә Сәяф белән Саматны. 16 яше тулар-тулмас, Кукмара киез итек фабрикасында эшләгән, тракторчылыкка укыган, Күкчәтау далаларында чирәм җирне күтәргән, Ленинградта армиядә хезмәт иткән һәм туган авылы Урта Кирмәнгә әйләнеп кайткан. Туганнарын эзләп тапкан. Алар янынннан кабат беркая да китмәскә, туган авылында калырга карар кылган. Кичке мәктәптә белем алып йөргәндә, укытучысы Гөлфәридә Минһаҗевнага гашыйк булган. Ике ятим шулай тормышларын нульдән башлап, гаилә корып җибәргәннәр. Якты дөньяга бер-бер артлы без – мәхәббәт чәчкәләре аваз салганбыз... Әкияттәге кебек өч кыз: Йолдыз, Алсу, Миләүшә. Апа белән сеңелкәшкә исемне әти кушкан, ә миңа – әни. Әти дә кушасы булган: «Артыкбикә», – дип. Чөнки арада аның өметен иң акламаганы – мин. Беренче кызларыннан соң, өзелеп, хыялланып малай көткән әти, ә монда кара көзнең иң сазлы, караңгы төнендә, дөньяны шәрран ярып, мин килеп чыкканмын. «Менә, Сәяф, тагын бер олы авызлы кызың бар», – дигәч, кулын селтәп, теге исемне әйткән дә тәмәке тартырга чыгып киткән әти. Ә төпчек Миләүшәне ул язмышы белән килешеп кабул итте. Сабый чактан ук алдыннан бер дә төшермәде. Өчебез дә рәхәтләнеп сыя идек без аның алдына. Әни белән бик кадерләп, иркәләп-назлап, муллыкта үстерделәр алар безне. Әле хәзер дә, инде 50нең аргы ягына чыккан кызлары турында чын-чынлап кайгыртып торалар.

Беркөнне эштә утырганда кинәт кенә искә төште дә: «Нишлисез?» – дип телефоннан шалтыраткан идем, «Менә урамга чыкканыем, кар ай-яй күп яуган, карап тордым-тордым да кердем», – ди әти. Ял көннәрендә кар көрәргә дип кайтсам, бөтен җир ялт иткән. Бәрәңге бакчасын да шулай итәләр алар әни белән – урталай бөкләнсәләр бөкләнәләр, эш бетмичә кермиләр. Үз эшләрен беркайчан кешедән эшләтмиләр, әле һаман бозау-сыер асрыйлар.

Әтинең ничек итеп гөмбә җыюын күрсәгез икән. Мин күрми киткәннәрен кәрҗине белән җыеп алды былтыр. Сабантуйларда картлар белән йөгерешкә дә бара иде әле ул, гел беренче килә иде, соңгы бер-ике елда гына: «Дәрт бар, дәрман юк!» – ди. Беркөнне почтага утка-суга түләргә баргач, чираттагы бөтен хатын-кызларны шаккатырып, әнигә Гашыйклар көненә открытка да алган. Кайсыгыз хатыны турында шулай кайгырта?! Бер-берсенә сюрпризны ясап кына торалар алар!!) Менә бу «Шәһри Казан« газетасы игълан иткән конкурс турында каян ишетеп, ник катнашырга уйладык дип уйлыйсыз?! Барысы да шул тиктормас, 57 ел бергә яшәгән иренә мәңге гашыйк Гөлфәридә аркасында. «Бәйгедә җиңәргә кирәк, атагызның беркайчан да артта калганы булмады, әтиегез – иң яхшысы!» – ди.

14 гыйнварда әтигә 80 яшь тулды. Юбилей җитәрәк, икәү генә калгач, әкрен генә сорадым мин моннан:

– Әти, сиңа нәрсә бүләк итик?

– Бер нәрсә дә кирәк түгел инде миңа хәзер, картайдым, – ди бу.

– Әти, барыбер ни дә булса алабыз бит инде, лутчы үзең әйт! – дим.

Уйлап-уйлап торды да:

– Армиядән кайтканда бик матур кәчтүм-чалбар сатып алган идем, шундый булса ярый, яшәсәм, киярмен, – ди бу.

Әлбәттә, эзләп таптык без аңа 21 яшьлек чагында армиядән кайткандагыдай кәчтүмне (әти дигәндә, тапмыйбызмы соң!), бик ошатты. Аллага шөкер, юбилейдан соң «икенче сулышы» ачылып, бик шат йөри әле, сөбханалла, күз тимәсен!

Алсу СПИРИДОНОВА,
Минзәлә.

Без – сугыш чоры балалары. Минем әтием дә, башка әтиләр белән берләттән, Совет Армиясе сафларына алына. Аннары илгә сугыш афәте янагач, яу кырына фашистлар белән көрәшергә китә. Яшь егет булып киткән булса да, саулыгын югалткан инвалид булып кына кайту насыйп була аңа. Ләкин монысы да зур бәхет бит. Бүтәннәр чит җирләрдә мәңгелеккә ятып та кала.

Әти күрә алмады...

Тормыш дәвам итә. Яшәргә дә, эшләргә дә кирәк. Тик җанга сугыш салган тирән яралар әрнүенә тән сызлаулары да кушылгач, төннәр тәмам газапка әйләнә. Дару эчеп яткач, бераз басылган кебек булалар да, аның көче беткәч, тагын сулкылдый башлыйлар. Ә бит яшисе килә, яшәргә кирәк! Яуда ятып калганнар өчен дә яшәргә кирәк исән кайтканнарга. Дүрт баланы да аякка бастырасы бар. Һәркем хәленнән килгәнчә колхозга булышырга тиеш. Әтиебез җәй айларында басу-кырларда, яшелчә басуларында каравылчы булып торды. Хәтеремдә,әни белән кыш көне урманнан чана тартып каен ботаклары ташып, өйдә аны себерке итеп бәйләп, тирә-юньдәге совхозларга тапшыралар да без балаларны кыш ашатып чыгарлык сугымлык ат алып кайталар.

Хәтеремдә, бер елны себерке тапшырып, әти кечкенә генә колын алып кайтты. Без балалар шул колынны җәй буе тәрбияләп, карап, көзгә елкылдап торган ат итеп үстердек. Гомерем буе, атлар күргән саен, әтине күргәндәй була идем.

Бакчабызда үскән бәрәңге дә безне ачлыктан йолып калды. Әтинең айлык пенсия акчасы – 18 сум, бу дарулар алырга да җитми иде. Кышларыбыз укып, ә яз-җәйләребез әти белән бергә кыр эшләрендә эшләп үтте. Әтиебезне югалтырга теләмәсәк тә, явыз язмыш безне иртә ятим итте, тирән яралары сызлау-әрнүдән, бөтенләйгә безнең арадан китте. Шунысы бик аяныч, хәзерге тормышны күрә алмый калды. Әтиебезнең кылган гамәлләре, игелекле хезмәтләре турында тагын да язарга булыр иде дә, хәтеремдә бик сакланмаган шул. Әле бүген дә сугыш дигән сүздән котым очып яшим. Аның ир-атларның яшьлекләрен, исәнлекләрен урлый, сабыйларны ятим итә, хатын-кызларны тол калдыра торган яман нәрсә икәнен без белдек инде, бүтәннәргә күрергә язмасын!

Миңлегөл ӘДҺӘМОВА,
Казан.

20 ФЕВРАЛЬ– ДҮШӘМБЕ

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05:00 «Җырлыйк әле!» (6+)
05:50 Татарстан хәбәрләре (12+)
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:00 Новости Татарстана (12+)
08:10 «Народный будильник» (12+)
09:00 «Так далеко, так близко». Телесериал (12+)
10:00 «Икенче туй». Телесериал (12+)
10:50 «Канун. Парламент Җәмгыять» (12+)
11:30 «Секреты татарской кухни» (12+)
12:00 «Подкидной». Телесериал (16+)
13:00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа (12+)
14:00 «Закон. Парламент. Общество» (12+)
14:30 Новости Татарстана (12+)
14:45 «Хочу мультфильм!» (0+)
15:00 «Күчтәнәч» (0+)
15:15 «Без тарихта эзлебез» (6+)
15:40 Мультфильмы (0+)
16:05 «Проделки Софи ». Мультсериал (0+)
17:00 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (0+)
17:30 «Елмай!» (12+)
17:40 «Икенче туй». Телесериал (12+)
18:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
19:00 «Прямая связь» (12+)
19:30 Новости Татарстана (12+)
20:00 «Вызов 112» (16+)
20:10 «Тукай урамында» (0+)
20:15 «Күчтәнәч» (0+)
20:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
21:00 «Кичке аш» (6+)
21:30 Новости Татарстана (12+)
22:00 «Вызов 112» (16+)
22:10 «Вечерняя игра» с Данияром Соколовым» (12+)

«ТНВ-ПЛАНЕТА»
06:00 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы (6+)
08:05 «Әдәби хәзинә» (12+)
08:30 «Яшәсен театр!» (0+)
09:00 «Яңалыклар» (12+)
09:20 «Онытa алмыйм». Ретро-концерт (0+)
10:05 «Кайнар хит» (12+)
11:00 «Татарлар» (12+)
11:30 «Белем дөньясы» (6+)
12:00 «Яңалыклар» (12+)
12:20 «Икенче туй». Телесериал (12+)
13:10 «Караоке татарча» (0+)
13:25 «Без тарихта эзлебез» (0+)
14:00 «Үткәннәр сагындыра» (0+)
14:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (0+)
15:00 «Яңалыклар» (12+)
15:15 «Күчтәнәч» (0+)
15:30 «Тамчы-шоу» (0+)
16:00 «Үткәннәр сагындыра» (0+)
16:10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
18:00 «Яңалыклар» (12+)
18:20 «Икенче туй». Телесериал (12+)
19:10 «Халкым минем» (12+)
19:40 «Туган җир» (12+)
20:05 «Татарлар» (12+)
20:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (0+)
21:00 «Яңалыклар» (12+)
21:20 «Күчтәнәч» (0+)
21:40 «Караоке татарча» (0+)
21:55 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт (0+)
22:45 «Таждай кояш нурлары». Татарстанның халык артисты Ринат Таҗетдинов турында телеочерк (6+)
23:35 «Яшәсен театр!» (0+)

«РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН»
6.05, 7.05, 8.05 «Вести – Татарстан. Погода»
6.35, 7.35, 8.35 «Вести – Татарстан. Утро»
11.40 «Парламентские вести»
14.40 «Яңалыклар. Татарстан»
17.20, 20.45 «Вести – Татарстан»

ПЕРВЫЙ
05.00 Телеканал «Доброе утро».
09.00 Новости.
09.20 Телеканал «Доброе утро».
09.55 Х/ф «Служебный роман».
12.00 Новости с субтитрами.
12.15 Х/ф «Служебный роман».
13.20 «Время покажет». (16+)
14.00 Новости.
14.15 «Время покажет». (16+)
15.00 Новости с субтитрами.
15.15 «Время покажет». (16+)
16.00 «Мужское / Женское». (16+)
17.00 «Давай поженимся!» (16+)
18.00 Прямой информационный канал «Первая Студия». (16+)
20.00 «Пусть говорят» с Андреем Малаховым. (16+)
21.00 Время.
21.35 Т/с Премьера. «Гречанка». (16+)
23.15 «Вечерний Ургант». (16+)
23.50 «Познер». (16+)

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России».
09.00 Вести.
09.15 «Утро России».
09.55 «О самом главном». (12+)
11.00 Вести.
11.40 Вести. Местное время.
11.55 Т/с «Каменская». (16+)
14.00 Вести.
14.40 Вести. Местное время.
14.55 Т/с «Тайны следствия». (12+)
17.00 Вести.
17.20 Вести. Местное время.
17.40 «Прямой эфир». (16+)
18.50 «60 минут». (12+)
20.00 Вести.
20.45 Вести. Местное время.
21.00 Т/с «Я всё помню». (12+)
23.30 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». (12+)
02.00 Т/с «Вольф Мессинг: Видевший сквозь время». (16+)

21 ФЕВРАЛЬ– СИШӘМБЕ

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05:00 «Музыкаль каймак» (12+)
05:50 Татарстан хәбәрләре (12+)
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:00 Новости Татарстана (12+)
08:10 «Народный будильник» (12+)
09:00 «Так далеко, так близко». Телесериал (12+)
10:00 «Икенче туй». Телесериал (12+)
10:50 «Туган җир» (12+)
11:30 «Секреты татарской кухни» (12+)
12:00 «Подкидной». Телесериал (16+)
13:00 «Путь» (12+)
13:15 «Если хочешь быть здоровым...» (6+)
13:30 Документальные фильмы (12+)
14:15 «Дорога без опасности» (12+)
14:30 Новости Татарстана (12+)
14:45 «Хочу мультфильм!» (0+)
15:00 «Күчтәнәч» (0+)
15:15 «Әдәби хәзинә» (12+)
15:40 Мультфильмы (0+)
16:05 «Проделки Софи». Мультсериал (0+)
17:00 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (0+)
17:30 «Елмай!» (12+)
17:40 «Татарстан без коррупции» (12+)
18:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
19:00 «Татарлар»12+
19:30 Новости Татарстана (12+)
20:00 «Вызов 112» (16+)
20:10 «Тукай урамында» (0+)
20:15 «Күчтәнәч» (0+)
20:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
21:00 «Кичке аш» (6+)
21:30 Новости Татарстана (12+)
22:00 «Вызов 112» (16+)
22:10 «Вечерняя игра» с Оскаром Юнусовым» (12+)
23:00 «Чёрное озеро» (16+)
23:30 «Грани «Рубина» (12+)

«ТНВ-ПЛАНЕТА»
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:05 «Без тарихта эзлебез» (0+)
08:30 «Яшәсен театр!» (0+)
09:00 «Яңалыклар» (12+)
09:20 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт (0+)
10:20 «Җырлыйк әле!» (6+)
11:10 «Татарлар» (12+)
11:30 «Халкым минем» (12+)
12:00 «Яңалыклар» (12+)
12:20 «Икенче туй». Телесериал (12+)
13:10 «Караоке татарча» (0+)
13:25 «Әдәби хәзинә» (12+)
14:00 «Үткәннәр сагындыра» (0+)
14:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (0+)
15:00 «Яңалыклар» (12+)
15:15 «Күчтәнәч» (0+)
15:30 «Поем и учим татарский язык» (0+)
15:45 «Җырлыйбыз да биибез» (0+)
16:00 «Үткәннәр сагындыра» (0+)
16:10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
18:00 «Яңалыклар» (12+)
18:20 «Икенче туй». Телесериал (12+)
19:10 «Башваткыч» (6+)
20:05 «Татарлар» (12+)
20:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (0+)
21:00 «Яңалыклар» (12+)
21:20 «Күчтәнәч» (0+)
21:40 «Караоке татарча» (0+)
21:55 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт (0+)
22:45 «Кыр казлары артыннан...». Илдар Юзеев турында телеочерк (6+)
23:35 «Яшәсен театр!» (0+)

«РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН»
6.05, 7.05, 8.05 «Вести – Татарстан. Погода»
6.35, 7.35, 8.35 «Вести – Татарстан. Утро»
9.00 «Мир культуры»
9.30 «Музыкальная жизнь»
11.40 «Вести – Татарстан»
14.40 «Яңалыклар. Татарстан»
17.20, 20.45 «Вести – Татарстан»

ПЕРВЫЙ
05.00 Телеканал «Доброе утро».
09.00 Новости.
09.20 Телеканал «Доброе утро».
09.50 «Жить здорово!» (12+)
10.55 Модный приговор.
12.00 Новости с субтитрами.
12.15 «Наедине со всеми». (16+)
13.20 «Время покажет». (16+)
14.00 Новости.
14.15 «Время покажет». (16+)
15.00 Новости с субтитрами.
15.15 «Время покажет». (16+)
16.00 «Мужское / Женское». (16+)
17.00 «Давай поженимся!» (16+)
18.00 Прямой информационный канал «Первая Студия». (16+)
20.00 «Пусть говорят» с Андреем Малаховым. (16+)
21.00 Время.
21.35 Т/с Премьера. «Гречанка». (16+)
23.15 «Вечерний Ургант». (16+)
23.50 Ночные новости.

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России».
09.00 Вести.
09.15 «Утро России».
09.55 «О самом главном». (12+)
11.00 Вести.
11.40 Вести. Местное время.
11.55 Т/с «Каменская». (16+)
14.00 Вести.
14.40 Вести. Местное время.
14.55 Т/с «Тайны следствия». (12+)
17.00 Вести.
17.20 Вести. Местное время.
17.40 «Прямой эфир». (16+)
18.50 «60 минут». (12+)
20.00 Вести.
20.45 Вести. Местное время.
21.00 Т/с «Я всё помню». (12+)
23.30 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». (12+)
02.00 Т/с «Вольф Мессинг: Видевший сквозь время». (16+)

22 ФЕВРАЛЬ– ЧӘРШӘМБЕ

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05:00 «Таяну ноктасы» (16+)
05:50 Татарстан хәбәрләре (12+)
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:00 Новости Татарстана (12+)
08:10 «Народный будильник» (12+)
09:00 « Так далеко, так близко ». Телесериал (12+)
10:00 «Икенче туй». Телесериал (12+)
10:50 «Ватандашлар». Телефильм (12+)
11:30 «Секреты татарской кухни» (12+)
12:00 «Подкидной». Телесериал (16+)
14:00 Документальный фильм (12+)
14:30 Новости Татарстана (12+)
14:45 «Хочу мультфильм!» (0+)
15:00 «Күчтәнәч» (0+)
15:15 «Яшьләр тукталышы» (12+)
15:40 Мультфильмы (0+)
16:05 «Проделки Софи». Мультсериал (0+)
17:00 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (0+)
17:30 «Елмай!» (12+)
17:40 «Икенче туй». Телесериал (12+)
18:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
19:00 Новости Татарстана (12+)
19:20 Хоккей. Кубок Гагарина. Матч серии play-off. Трансляция из Казани (12+)
22:00 «Вызов 112» (16+)
22:10 «Вечерняя игра» с Михаилом Основым» (12+)

«ТНВ-ПЛАНЕТА»
06:00 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы (6+)
08:05 «Әдәби хәзинә» (12+)
08:30 «Яшәсен театр!» (0+)
09:00 «Яңалыклар» (12+)
09:20 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт (0+)
10:20 «Башваткыч» (6+)
11:10 «Татарлар» (12+)
11:30 «Туган җир» (12+)
12:00 «Яңалыклар» (12+)
12:20 «Икенче туй». Телесериал (12+)
13:10 «Караоке татарча» (0+)
13:25 «Без тарихта эзлебез» (0+)
14:00 «Үткәннәр сагындыра» (0+)
14:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (0+)
15:00 «Яңалыклар» (12+)
15:15 «Күчтәнәч» (0+)
15:30 «Поем и учим татарский язык» (0+)
15:45 «Җырлыйбыз да биибез» (0+)
16:00 «Үткәннәр сагындыра» (0+)
16:10 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы (6+)
18:00 «Яңалыклар» (12+)
18:20 «Икенче туй». Телесериал (12+)
19:10 «Таяну ноктасы» 16+
20:05 «Татарлар» (12+)
20:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (0+)
21:00 «Яңалыклар» (12+)
21:20 «Күчтәнәч» (0+)
21:40 «Караоке татарча» (0+)
21:55 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт (0+)
22:45 «Бәргәләнмә, күңел кошым...». Әзһәр Шакиров (6+)
23:35 «Яшәсен театр!» (0+)

«РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН»
6.05, 7.05, 8.05 «Вести – Татарстан. Погода»
6.35, 7.35, 8.35 «Вести – Татарстан. Утро»
11.40 «Вести – Татарстан»
14.40 «Яңалыклар. Татарстан»
17.20, 20.45 «Вести – Татарстан»

ПЕРВЫЙ
05.00 Телеканал «Доброе утро».
09.00 Новости.
09.20 Телеканал «Доброе утро».
09.50 «Жить здорово!» (12+)
10.55 Модный приговор.
12.00 Новости с субтитрами.
12.15 «Наедине со всеми». (16+)
13.20 «Время покажет». (16+)
14.00 Новости.
14.15 «Время покажет». (16+)
15.00 Новости с субтитрами.
15.15 «Время покажет». (16+)
16.00 «Мужское / Женское». (16+)
17.00 «Давай поженимся!» (16+)
18.00 Вечерние новости с субтитрами.
18.45 «Человек и закон» с Алексеем Пимановым. (16+)
19.50 «Поле чудес». (16+)
21.00 Время.
21.30 «Голос. Дети». Новый сезон.
23.20 «Вечерний Ургант». (16+)
00.00 Х/ф «Одержимость». (16+)
02.00 Х/ф «Короли улиц-2: Город моторов». (18+)

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России».
09.00 Вести.
09.15 «Утро России».
09.55 «О самом главном». (12+)
11.00 Вести.
11.40 Вести. Местное время.
11.55 Т/с «Каменская». (16+)
14.00 Вести.
14.40 Вести. Местное время.
14.55 Т/с «Тайны следствия». (12+)
17.00 Вести.
17.20 Вести. Местное время.
17.40 «Прямой эфир». (16+)
18.50 «60 минут». (12+)
20.00 Вести.
20.45 Вести. Местное время.
21.00 Т/с «Я всё помню». (12+)
23.30 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». (12+)
02.00 Т/с «Вольф Мессинг: Видевший сквозь время». (16+)
04.05 Х/ф «Мы с вами где-то встречались».

23 ФЕВРАЛЬ– ПӘНҖЕШӘМБЕ

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05:00 «Башваткыч» (6+)
05:50 Татарстан хәбәрләре (12+)
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:00 Новости Татарстана (12+)
08:10 «Народный будильник» (12+)
09:00 «Сказка о потерянном времени». Художественный фильм для детей (0+)
10:25 Мультфильмы (0+)
10:50 «Белем дөньясы» (6+)
11:30 «Секреты татарской кухни» (12+)
12:00 «Улым». Гүзәл Уразова һәм Илдар Хакимов концерты (0+)
14:30 Новости Татарстана (12+)
14:45 «Тегеран-43». Художественный фильм (0+)
17:30 «Җырларым яшәтсен, яшәртсен иде...». Раяз Фасыйхов (0+)
18:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
19:00 «Татарлар» (12+)
19:30 Новости Татарстана (12+)
20:00 «Вызов 112» (16+)
20:10 «Тукай урамында» (0+)
20:15 «Күчтәнәч» (0+)
20:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
21:00 «Кичке аш» (6+)
21:30 Новости Татарстана (12+)
22:00 «Вызов 112» (16+)
22:10 «72 метра». Художественный фильм (12+)

«ТНВ-ПЛАНЕТА»
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:05 «Без тарихта эзлебез» (0+)
08:30 «Яшәсен театр!» (0+)
09:00 «Яңалыклар» (12+)
09:20 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт (0+)
10:15 «Таяну ноктасы» 16+
11:10 «Татарлар» (12+)
11:30 «Яшьләр тукталышы» (12+)
12:00 «Яңалыклар» (12+)
12:20 «Икенче туй». Телесериал (12+)
13:10 «Әдәби хәзинә» (12+)
13:35 «Идрис Газиев тәкъдим итә. Җырлы-моңлы сынчы, тылсымчы. Бакый Урманче» (6+)
14:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (0+)
15:00 «Яңалыклар» (12+)
15:15 «Күчтәнәч» (0+)
15:30 «Поем и учим татарский язык» (0+)
15:45 «Җырлыйбыз да биибез» (0+)
16:00 «Үткәннәр сагындыра» (0+)
16:10 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы (6+)
18:00 «Яңалыклар» (12+)
18:20 «Икенче туй». Телесериал (12+)
19:10 «Ком сәгате» (12+)
20:05 «Татарлар» (12+)
20:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (0+)
21:00 «Яңалыклар» (12+)
21:20 «Күчтәнәч» (0+)
21:40 «Караоке татарча» (0+)
21:55 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт (0+)
22:45 «Идрис Газиев тәкъдим итә. Җырлы-моңлы сынчы, тылсымчы. Бакый Урманче» (6+)
23:35 «Яшәсен театр!» (0+)

«РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН»
Вещание не предусмотрено

ПЕРВЫЙ
06.00 Новости.
06.10 Д/с «Россия от края до края».
06.40 Х/ф «Отряд особого назначения». (12+)
08.10 Х/ф «Служили два товарища».
10.00 Новости с субтитрами.
10.10 Х/ф «Офицеры». Легендарное кино в цвете.
12.00 Новости с субтитрами.
12.10 Концерт, посвященный фильму «Офицеры» в Государственном Кремлевском Дворце.
13.45 Т/с Премьера. «Нулевая Мировая». (16+)
15.50 Х/ф Премьера. «Боевая единичка». (12+)
18.00 Вечерние новости с субтитрами.
18.10 Х/ф «Боевая единичка». (12+)
19.45 Премьера. Концерт к Дню защитника Отечества.
21.00 Время.
21.20 Концерт к Дню защитника Отечества.
22.30 Х/ф «В бой идут одни «старики».
00.15 Х/ф «Ожидание полковника Шалыгина». (12+)
01.55 Х/ф «Старое ружье». (16+)

РОССИЯ 1
06.05 Х/ф «Старики-разбойники».
08.00 Х/ф «Сюрприз для любимого».
10.00 Т/с «Затмение». (12+)
14.00 Вести.
14.20 Т/с «Затмение». (12+)
18.05 Х/ф «Джентльмены удачи».
20.00 Вести.
20.40 Х/ф «Экипаж». (12+)
23.30 Х/ф «Легенда №17». (12+)

24 ФЕВРАЛЬ– ҖОМГА

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05:00 «Халкым минем...» (12+)
05:25 «Нәсыйхәт» (6+)
05:50 Татарстан хәбәрләре (12+)
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:00 Новости Татарстана (12+)
08:10 «Народный будильник » (12+)
09:00 «Обыкновенное чудо». Художественный фильм (0+)
11:30 «Секреты татарской кухни» (12+)
12:00 «Сайра, сайра, сандугач...». Хәмдүнә Тимергалиева (0+)
13:00 «Таяну ноктасы» (16+)
14:00 «Актуальный ислам» (6+)
14:15 «Все суры Корана» (6+)
14:30 Новости Татарстана (12+)
14:45 М. Фәйзи. «Нәзер». М. Фәйзи исемендәге Оренбург татар дәүләт драма театры спектакле (12+)
16:45 Хоккей. Кубок Гагарина. Матч серии play-off. Трансляция из Казани (12+)
19:30 Новости Татарстана (12+)
20:00 «Вызов 112» (16+)
20:10 «Тукай урамында» (0+)
20:15 «Күчтәнәч» (0+)
20:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
21:00 «Кичке аш» (6+)
21:30 Новости Татарстана (12+)
22:00 «Вызов 112» (16+)
22:10 «Мисс Татарстан-2017». XIX Республиканский конкурс красоты (12+)

«ТНВ-ПЛАНЕТА»
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:05 «Нәсыйхәт» (6+)
08:30 «Яшәсен театр!» (0+)
09:00 «Яңалыклар» (12+)
09:20 «Музыкаль каймак» (12+)
10:00 «Караоке татарча» (0+)
10:15 «Ком сәгате» (12+)
11:10 «Татарлар» (12+)
11:30 «Кичке аш» (6+)
12:00 «Яңалыклар» (12+)
12:20 «Икенче туй». Телесериал (12+)
13:10 «Караоке татарча» (0+)
13:25 «Нәсыйхәт» (6+)
14:00 «Үткәннәр сагындыра» (0+)
14:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (0+)
15:00 «Яңалыклар» (12+)
15:15 «Күчтәнәч» (0+)
15:30 «Поем и учим татарский язык» (0+)
15:45 «Җырлыйбыз да биибез» (0+)
16:00 «Үткәннәр сагындыра» (0+)
16:10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
18:00 «Яңалыклар» (12+)
18:20 «Икенче туй». Телесериал (12+)
19:10 «Иң... Иң... Иң...». Россиянең һәм Татарстанның халык артисты Алсу Гайнуллина (6+)
20:05 «Татарлар» (12+)
20:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (0+)
21:00 «Яңалыклар» (12+)
21:20 «Күчтәнәч» (0+)
21:40 «Караоке татарча» (0+)
21:55 «Музыкаль каймак» (12+)
22:45 «Иң... Иң... Иң...». Россиянең һәм Татарстанның халык артисты Алсу Гайнуллина (6+)
23:35 «Яшәсен театр!» (0+)

«РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН»
Вещание не предусмотрено

ПЕРВЫЙ
05.45 Д/с «Россия от края до края».
06.00 Новости.
06.10 Д/с «Россия от края до края».
06.40 Х/ф «Корпус генерала Шубникова». (12+)
08.20 Х/ф «Это случилось в милиции».
10.00 Новости с субтитрами.
10.10 Х/ф «Раба любви». (12+)
12.00 Новости с субтитрами.
12.15 Х/ф «Вам и не снилось...»
14.00 Т/с Премьера. «Нулевая Мировая». (16+)
16.00 Д/ф Премьера. «Они хотели меня взорвать». Исповедь русского моряка». (12+)
17.10 Х/ф «Небесный тихоход». Кино в цвете.
18.45 Премьера. Юбилей Николая Расторгуева.
21.00 Время.
21.20 Х/ф Премьера. «Батальон». (12+)
23.40 Х/ф «Хоть раз в жизни». (16+)
01.40 Х/ф «Маргарет». (16+)
04.30 «Модный приговор».

РОССИЯ 1
05.40 Х/ф «Кандагар». (16+)
07.45 Х/ф «Легенда №17». (12+)
10.35 Х/ф «Джентльмены удачи».
12.20 Х/ф «Ключи от прошлого». (12+)
14.00 Вести.
14.20 Х/ф «Ключи от прошлого». (12+)
20.00 Вести.
20.40 Х/ф «Завтрак в постель». (12+)
00.30 Х/ф «В тесноте, да не в обиде». (12+)

25 ФЕВРАЛЬ – ШИМБӘ

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05:00 Концерт (6+)
07:00 «Sиңа Миннән Sәлам» (6+)
09:00 «Автомобиль» (12+)
09:30 «ДК» (12+)
09:45 «Здоровая семья: мама, папа и я» (6+)
10:00 «Кайнар хит» (12+)
11:00 «Халкым минем...» (12+)
11:30 «Секреты татарской кухни» (12+)
12:00 «Каравай» (0+)
12:30 «Видеоспорт» (12+)
13:00 «Канун. Парламент Җәмгыять» (12+)
13:30 «Кемгә – юмор, кемгә - җыр». Җәвит Шакировның юбилей концерты (12+)
16:00 «Нәсыйхәт» (6+)
16:30 «Татарлар» (12+)
17:00 «Родная земля» (12+)
17:30 «Әдәби хәзинә» (12+)
18:00 «КВН РТ-2017» (12+)
19:00 «Среда обитания» (12+)
19:30 Новости в субботу (12+)
20:00 «Адымнар» (12+)
20:30 «Җырлыйк әле!» (6+)
21:30 Новости в субботу (12+)
22:00 «Старики-разбойники». Художественный фильм (12+)
23:40 «Вопреки здравому смыслу». Художественный фильм (16+)
01:15 «Тузган тороктан күчкәндә ». Телевизион нәфис фильм (12+)

«ТНВ-ПЛАНЕТА»
06:00 «Идрис Газиев тәкъдим итә. Җырлы-моңлы сынчы, тылсымчы. Бакый Урманче» (6+)
07:00 «Sиңа Миннән Sәлам» (6+)
09:00 «Шаян хәлләр» (16+)
10:00 «Кайнар хит» (12+)
11:00 «Башваткыч» (6+)
11:50 «Җырлыйк әле!» (6+)
12:40 «Җыр булыр идем». Татарстанның атказанган артисты Рөстәм Асаев концерты (6+)
14:30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» (12+)
15:00 «Sиңа Миннән Sәлам» (6+)
17:00 «Кайнар хит» (12+)
18:00 «Таяну ноктасы» 16+
18:55 «Кичке аш» (6+)
19:20 «Башваткыч» (6+)
20:10 «Җырлыйк әле!» (6+)
21:00 «Адымнар» (12+)
21:30 «Бәйрәм бүген!». «Казан егетләре» концерты (6+)
23:15 Н.Исәнбәт. «Хуҗа Насретдин». К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры спектакле (12+)
01:45 «Чатыртау моңнары». Шагыйрь Рөстәм Зәкуанов җырлары (12+)

«РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН»
8.00, 11.20 «Вести - Татарстан»
8.20 «Доброе утро, Татарстан!»

ПЕРВЫЙ
05.30 «Наедине со всеми». (16+)
06.00 Новости.
06.10 «Наедине со всеми». (16+)
06.30 Х/ф «По законам военного времени». (12+)
08.00 Играй, гармонь любимая!
08.45 М/с «Смешарики. Новые приключения».
09.00 Умницы и умники. (12+)
09.45 Слово пастыря.
10.00 Новости с субтитрами.
10.15 Смак. (12+)
10.55 Д/ф Премьера. «Вера Алентова. «Я покажу вам королеву-мать!» К юбилею актрисы. (12+)
12.00 Новости с субтитрами.
12.10 Х/ф «Зависть богов». (16+)
14.45 Х/ф «Дачная поездка сержанта Цыбули». (12+)
16.10 «Голос. Дети».
18.00 Вечерние новости с субтитрами.
18.15 «Кто хочет стать миллионером?» с Дмитрием Дибровым.
19.10 Минута славы. Новый сезон.
21.00 Время.
21.20 «Сегодня вечером» с Андреем Малаховым. (16+)
23.00 Х/ф Премьера. «Невероятная жизнь Уолтера Митти». (12+)
01.00 Х/ф «Жизнь хуже обычной». (16+)
03.00 Х/ф «Исчезающая точка». (16+)

РОССИЯ 1
05.15 Т/с «Частный детектив Татьяна Иванова». (12+)
07.10 «Живые истории».
08.00 Вести. Местное время.
08.20 Россия. Местное время. (12+)
09.20 Сто к одному.
10.10 «Семейный альбом». (12+)
11.00 Вести.
11.20 Вести. Местное время.
11.40 Аншлаг и Компания. (16+)
14.00 Вести.
14.20 Х/ф «Один единственный и навсегда». (12+)
18.00 Субботний вечер.
20.00 Вести в субботу.
21.00 Х/ф «За полчаса до весны». (12+)
0.55 Х/ф «Путь к сердцу мужчины». (12+)

26 ФЕВРАЛЬ– ЯКШӘМБЕ

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
Вниманию телезрителей! Телеканал ТНВ планирует вести прямую трансляцию матчей серии play-off Кубка Гагарина. Пожалуйста, следите за изменениями в программе передач!
05:00 Концерт (6+)
08:00 «Адымнар» (12+)
08:30 Мультфильмы (0+)
09:00 «ДК» (12+)
09:15 Документальный фильм (12+)
09:45 «Тамчы-шоу» (0+)
10:15 «Яшьләр тукталышы» (12+)
10:45 «Музыкаль каймак» (12+)
11:30 «Секреты татарской кухни» (12+)
12:00 «Среда обитания» (12+)
12:30 «Каравай» (0+)
13:00 «Закон. Парламент. Общество» (12+)
13:30 «Адымнар» (12+)
14:00 «Йөрәктән – йөрәккә». Композитор Рөстәм Яхин турында телеочерк (6+)
15:00 «Ком сәгате» (12+)
16:00 «Таяну ноктасы» (16+)
17:00 «Видеоспорт» (12+)
17:30 «Әдәби хәзинә» (12+)
18:00 «Башваткыч» (6+)
19:00 Телефильм (12+)
19:15 «Профсоюз – союз сильных» (12+)
19:30 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа (12+)
20:30 «Болгар радиосы» концерты (6+)
21:30 «Кичке аш» (6+)
22:00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа (12+)
23:00 «Любить нельзя забыть». Художественный фильм (16+)

«ТНВ-ПЛАНЕТА»
06:00 «Илнар Ялалов концерты» (6+)
07:25 «Казан нуры» халык уен кораллары оркестры концерты (6+)
09:25 «Яшьләр тукталышы» (12+)
09:55 «Тамчы-шоу» (0+)
10:20 «Поем и учим татарский язык» (0+)
10:30 «Җырлыйбыз да биибез» (0+)
11:00 «Белем дөньясы» (6+)
11:30 «Халкым минем» (12+)
12:00 «Онытасым килми сине». Шамил Шәрипов җырлары (0+)
12:30 «Татарлар» (12+)
13:00 «Нәсыйхәт» (6+)
13:30 «Безнең җыр». Асылъяр (6+)
15:50 ТВ фондыннан. «Палитра». Бакый Урманче (6+)
16:30 «Музыкаль каймак» (12+)
17:20 «Әдәби хәзинә» (6+)
17:50 «Без тарихта эзлебез» (0+)
18:20 «Болгар радиосы» концерты (12+)
19:10 «Ком сәгате» (12+)
20:05 «Кемгә – юмор, кемгә – җыр». Җәвит Шакировның юбилей кичәсе» (6+)
22:25 «Йөрәктән – йөрәккә». Сара Садыйкова (6+)
23:20 «Халкым минем» (12+)
23:45 «Ком сәгате» (12+)

«РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН»
10.20 «Вести – Татарстан. События недели»

ПЕРВЫЙ
05.45 «Наедине со всеми». (16+)
06.00 Новости.
06.10 «Наедине со всеми». (16+)
06.40 Х/ф «Фиктивный брак». (16+)
08.10 М/с «Смешарики. Пин-код».
08.25 «Часовой». (12+)
08.55 «Здоровье». (16+)
10.00 Новости с субтитрами.
10.15 «Непутевые заметки» с Дмитрием Крыловым. (12+)
10.35 «Пока все дома».
11.25 Фазенда.
12.00 Новости с субтитрами.
12.10 Х/ф «Свадьба в Малиновке».
14.00 Х/ф «Полосатый рейс». (12+)
15.40 Х/ф «Экипаж». (12+)
18.30 Д/ф Премьера. «Лучше всех!» Рецепты воспитания».
19.30 Премьера. «Лучше всех!»
21.00 Воскресное «Время».
22.30 «Клуб Веселых и Находчивых». Высшая лига. (16+)
00.45 Х/ф «Вечное сияние чистого разума». (16+)
02.50 Х/ф «Зажигай, ребята!» (16+)

РОССИЯ 1
05.00 Т/с «Частный детектив Татьяна Иванова». (12+)
07.00 Мульт-утро.
07.30 «Сам себе режиссёр».
08.20 «Смехопанорама» Евгения Петросяна.
08.50 Утренняя почта.
09.30 Сто к одному.
10.20 Местное время. Вести-Москва. Неделя в городе.
11.00 Вести.
11.20 Смеяться разрешается.
14.00 Вести.
14.20 Х/ф «Цена измены». (12+)
16.15 Х/ф «Украденное счастье». (12+)
20.00 Вести недели.
22.00 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». (12+)
00.30 Д/ф «Алексей Брусилов. Служить России». (12+)

Первый, Россия1 каналларының программасы «Сервис-ТВ» АҖдан алынды

«ТАТАРСТАН» радиосы

20 ФЕВРАЛЬ – ДҮШӘМБЕ

6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы
6.04 «Нефть чыккан якларда»
6.15 «Музыкаль мизгелләр»
6.35, 10.00, 18.10 Яңалыклар. Новости
6.45 «Юллар чатында»
6.50,7.50,10.10,10,55,13.55,18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-10.00,11.00-12.10,13.00-13.10, 14.00-18.10,19.00 Трансляция радио России
10.20, 13.10 Рәфкать Кәрами. «Каргышлы этаплар». Радиотамаша. 3-4нче өлешләр
12.10-13.00 «Татарстан дулкынында».
18.25 «Сердәшханә»
18.40 «Жыр – минем гомерлек юлдашым». Инсаф Исламов

21 ФЕВРАЛЬ – СИШӘМБЕ

6.00-8.00 «Новый день». Панорама событий
6.04 «Актуальное интервью»
6.15 «Музыкаль мизгелләр»
6.35,10.00,13.10,18.10 Яңалыклар. Новости
6.50,7.50,10.50,13.45,18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Диалог в прямом эфире
8.00-10.00,11.00-12.10,13.00-13.10, 14.00-18.10,19.00 Трансляция радио России
10.10 «Депутатский канал»
12.10 «Татарстан дулкынында»
13.20 Концерт
18.25 Лирик концерт

22 ФЕВРАЛЬ – ЧӘРШӘМБЕ

6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы
6.04 «Нефть чыккан якларда»
6.15 «Музыкаль мизгелләр»
6.35,10.00,13.10,18.10 Яңалыклар. Новости
6.50,7.50,10.10,10.50,13.55,18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-10.00,11.00-12.10,13.00-13.10, 14.00-18.10,19.00 Трансляция радио России
10.20 «Актуальное интервью»
10.35 «Старт»
12.10-13.00 «Татарстан дулкынында»
13.20 «Яшьлек аланы»
18.25 Айдар Галимов концерты

23 ФЕВРАЛЬ – ПӘНҖЕШӘМБЕ

ВАТАННЫ САКЛАУЧЫЛАР КӨНЕ

10.10 «Время молодых». Беседа с начальником отдела Военного комиссариата РТ Д.В.Гурылевым.
10.55 Реклама, прогноз погоды
12.10-13.00 «Татарстан дулкынында»
13.10 «Солдатта булган диләр...» Концерт.
13.55 Реклама, прогноз погоды
14.00 Трансляция радио России

24 ФЕВРАЛЬ – ҖОМГА

10.10 «Вдохновенья миг»
10.55 Реклама, прогноз погоды
12.10-13.00 «Татарстан дулкынында»
13.10 «Музыкаль очрашулар». Гобойчы Мөбарәк Батталов, жырчы Рәйсә Билалова
13.55 Реклама, прогноз погоды
14.00 Трансляция радио России

25 ФЕВРАЛЬ – ШИМБӘ

10.10 «Язучылар-балаларга»
10.30 «7 көн». Атналык күзәтү
10.55,13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.00-12.10,13.00-13.10,14.00-15.10, 16.00 Трансляция радио России
12.10-13.00 «Татарстан дулкынында»
13.10 Татар халык көйләре
15.10 Гильерме Фигейредо. «Эзоп». Г.Камал ис.ТДАТ спектакленең радиоварианты. 1нче өлеш

26 ФЕВРАЛЬ – ЯКШӘМБЕ

8.00-9.00 «Между Волгой и Уралом». Объединенный радиожурнал семи республик
9.00-10.10,11.00-12.10,13.00-13.10, 14.00-15.10,16.00-16.10,17.00 Трансляция радио России
10.10 «Көмеш кыңгырау»
10.30 «7 дней». Обзор событий
10.55,13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
12.10-13.00 «Татарстан дулкынында»
13.10 Ял концерты
15.10,16.10 Гильерме Фигейредо. «Эзоп». 2-3нче өлешләр

«ТӘРТИП» радиосы

20 ФЕВРАЛЬ – ДҮШӘМБЕ

6.05 Иртәнге гимнастика (12+)
7.05 «Тукай укулары» (12+)
10.35 «Кабатланмас моңнар» (12+)
11.05 «И Казан, Дәртле Казан, Моңлы Казан!» (кабатлау) (12+)
12.30 Акыл гимнастикасы (12+)
13.05 «Тукай укулары» (кабатлау) (12+)
15.05 «И Казан, Дәртле Казан, Моңлы Казан!» (кабатлау) (12+)
16.05 Мөһаҗирләр (12+)
19.05 «Тукай укулары» (кабатлау) (12+)
20.05 «Кабатланмас моңнар» (12+)

21 ФЕВРАЛЬ – СИШӘМБЕ

6.05 Иртәнге гимнастика (12+)
10.05 «Безнең мирас» (12+)
10.35 Офис гимнастикасы (12+)
11.05 «Риваять» (кабатлау) (12+)
11.40 Рухият (12+)
12.30 Акыл гимнастикасы (12+)
13.05 «Әдәби мирас» (12+)
16.05 «Безнең мирас» (12+)
19.05 «Әдәби мирас» (12+)
21.00 «Безнең спорт» (кабатлау) (12+)

22 ФЕВРАЛЬ – ЧӘРШӘМБЕ

6.05 Иртәнге гимнастика (12+)
8.05 «Бакча – җимеше, кеше эше белән» (кабатлау) (12+)
10.35 Офис гимнастикасы (12+)
12.30 Акыл гимнастикасы (12+)
14.00 «Чакырылган кунак» (12+)
17.05 «Бакча – җимеше, кеше эше белән» (кабатлау) (12+)
19.07 «Язмышлар чатында» (12+)

23 ФЕВРАЛЬ – ПӘНҖЕШӘМБЕ

6.05 Иртәнге гимнастика (12+)
7.05 «Тел дигән дәрья бар» (12+)
10.05 «Мөһаҗирләр» (12+)
10.35 Офис гимнастикасы (12+)
12.30 Акыл гимнастикасы (12+)
13.05 «Тел дигән дәрья бар» (кабатлау) (12+)
16.05 «Мөһаҗирләр» (12+) (кабатлау)
19.05 «Тел дигән дәрья бар» (кабатлау) (12+)
21.00 «Калеб». Яңа буын иҗатчылары (12+)

24 ФЕВРАЛЬ – ҖОМГА

6.05 Иртәнге гимнастика (12+)
7.05 «Тузмый торган бүләк» (12+)
11.05 «И Казан, Дәртле Казан, Моңлы Казан!» (12+)
12.30 Акыл гимнастикасы (12+)
13.05 «Тузмый торган бүләк» (кабатлау) (12+)
11.05 «И Казан, Дәртле Казан, Моңлы Казан!» (кабатлау) (12+)
19.05 «Тузмый торган бүләк» (кабатлау) (12+)
21.00 «Безнең спорт» (12+)

25 ФЕВРАЛЬ – ШИМБӘ

6.05 Иртәнге гимнастика (12+)
8.05 «Бакча – җимеше, кеше эше белән» (12+)
10.05 «Безнең мирас» (кабатлау) (12+)
10.35 Офис гимнастикасы (12+)
12.30 Акыл гимнастикасы (12+)
13.05 «Галиҗәнап театр» (12+)
16.05 «Язмышлар чатында» (кабатлау) (12+)
17.05 «Бакча – җимеше, кеше эше белән» (кабатлау) (12+)
18.05 «Галиҗәнап театр» (кабатлау) (12+)
19.00 Әдәби мирас (кабатлау) (12+)
20.05 «Кабатланмас моңнар» (кабатлау) (12+)
21.00 «Калеб» (кабатлау) (12+)
22.00 «Әдәби мизгел» (12+)

26 ФЕВРАЛЬ – ЯКШӘМБЕ

6.05 Иртәнге гимнастика (12+)
10.05 «Тукай укулары» (кабатлау) (12+)
11.05 «Риваять» (12+)
12.30 Акыл гимнастикасы (12+)
13.05 «Тузмый торган бүләк» (кабатлау) (12+)
15.05 «Риваять» (кабатлау) (12+)
16.07 «Тел дигән дәрья бар» (кабатлау) (12+)
19.07 «Галиҗәнап театр» (кабатлау) (12+)
21.00 «Чакырылган кунак» (12+)

СКАНВОРД



Фаил Гаязов төзеде

Горизонталь буенча: ас, Анкара, крокодил, ню, плитка, да, Луи, «Апа», ар, Римма, Луиза, Аза, зело, талон, «Ив», Апе, «Норд», «Амкар», сират, Диана, Австралия, ил, гну, нигез, комсомол, ачы, «Кино», як, Әюпов, лат, «ШПА», Индира.
Вертикаль буенча: «Апама», искәрмә, илбасар, сату, па, Кираметдинов, ара, им, Айгөл, код, Амазонка, зат, Анна, Лир, алкыш, Пловдив, ау, сумка, ром, си, аз, Риони, Карратрака, Мон, лак, «Игл», ян, яр, Ләйсән, РФ, Умка.

Аңлашу

Макдоналдс. Чибәр кыз. Мине күрү белән иренена елмаю куна.

– Саумысыз. Нәрсә аласыз?

– Биш бигмак.

– Тагын бәрәңге-фри дә теләмисезме?

– Юк.

– Ә, бәлки, кола кирәктер?

– Юк.

– Круассан?

– Юк.

– Десерт?

– Юк.

– Яхшы, ә бигмак нәрсә белән?

– Ну...

– Соус яки кетчуп?

– Юк.

– Бик яхшы соус бар...

– Юк, юк... Башка берни дә кирәкми...

Миңа булган игътибар сүрелә, кызның иренендәге елмаю шуып төшә. Мин тыныч кына заказны көтәм. Китерәләр. Кыз нидер исәпли, шуннан, зур тырышлык белән, тиге елмаюын кия. Миңа төбәлә.

– Сездән фәлән сум фәлән тиен.

Мин кәшилүкне чыгарам. Һәм кинәт...

Кинәт миңа шулкадәр кызык булып тоела... Илһам килә... Аның елмаюын кабатлыйм:

– Ә сезгә кәгазь акчамы, тиеннәр беләнме?

Кызның елмаюы югала. Күзе маңгаена менә.

– Мөһим түгел.

– Яхшы, алайса, кәгазь акча. Сезгә йөзлекләр беләнме, әллә иллелекме?

– Нууу...

– Яхшы. Иллелекләр. Ә, бәлки, яртысын тиеннәр белән бирергәдер?

– Нууу...

– Сезгә бишлекләрме, әллә бер сумлыкларммы?

– Әәәә...

– Илле тиенлекләр белән ун тиенлекләр дә бар. Сезгә кайсы кирәк?

– Мммм...

Тирә-яктагылар барысын да ишетеп тора. Күпләре инде ачыктан-ачык көлә башлый. Мин дәвам итәм.

– Ну, ярый алайса, банк картасы белән исәпләшербез. Мөмкинме?

– Ыһы.

– Ә сезгә нинди банк уңайлырак – Сбербанкмы, әллә...

Халык көлә.

Кыз кызара.

Мин тиешле сумманы исәпләп бирәм.

Кыз, рәхмәт укып, күздән югала. Алкышлар.

Марат КӘБИРОВ.

ТАШКА БАСКАН

✓ Табигый акылдан коты алынган кешелек ясалма акыл уйлап табарга омтыла.

* * *

✓ Ахмаклыкның файдасы тия икән, димәк, ул ахмаклык түгел.

* * *

✓ Чиновникларның урынын алыштырудан ришвәт суммасы үзгәрми.

* * *

✓ Койрык болгаганда, теш күрсәтмиләр.

* * *

✓ Бәхет өчен көрәш күп очракта ялкаулык белән көрәшүгә кайтып кала.

* * *

✓ Акчаны акыл белән тоту өчен, акчаң һәм акылың булу гына җитми.

* * *

✓ Җилкәндәге акыллы хатынның аврырлыгын тоймыйсың.

* * *

✓ Мин диетага утырдым, спорт белән шөгыльләнә башладым һәм 14 көн эчендә ике атнаны югалттым.

* * *

✓ Үзләре ук җинаятьчелеккә каршы көрәшкән полиция үзе җинаять кылырга тиеш түгел дисезме? Нигә алай булсын ди әле?! Табиблар да авырый бит.

***

✓ Аңлап булмый бу ир-атларны. Алар, калкавыч селкенгәнне көтеп, ике сәгать буе тын да алмыйча утырырга мөмкиннәр. Ә минә хатыннарының биш минут киенгәнен көтәргә нервылары җитми.

***

✓ Йөргән кызым әйтүенчә, безнең мәхәббәтне бары тик могҗиза яки яңа тун гына саклап калырга мөмкин.

4 мәзәк

* * *

– Син мине кара кенәгәгә керттеңме әллә?

– Юк, мин сине Кызыл китапка керттем. Берәү генә калган сирәк хайван буларак.

* * *

– Бүген эштән иртәрәк китсәм ярыймы? Бик җитди сәбәбе бар иде.

– Нинди сәбәп?

– Монда торасым килми.

* * *

Коткаручылар Чулман елгасында агып киткән боз өстеннән 160 балыкчы белән бергә 16 әрҗә аракы һәм 16 балык та алып чыккан.

* * *

«Коррупциягә каршы көрәш» конференциясендәге чыгышларның берсендә әйтелгәннәрдән: «Моннан соң түрәләр чалбардагы сул кесәләрен генә түгел, уң яктагысын да әйләндереп күрсәтергә тиеш! Беләм, күпләрдә мондыйрак сорау да туарга мөмкин: ә алар ришвәткә алган акчаны кулмәк кесәсенә тыккан булса? Алай да булуы ихтимал. Тик чалбар кесәләренең берьюлы икесен тикшерүнең дә коррупциягә каршы көрәштә ясалган зур адым булуын танымый мөмкин түгел».



Ак хыял

Рифат СӘЛАХ

Иңнәреңә ап-ак канат итеп
Ак күлмәгең киеп җай гына
Хыялыма килеп кергән идең
Күңелнең иң сада чагында.

Буй җитмәслек
Якты хыялдыр син,
Йөзәсеңдер йолдыз күлендә...
Син елмайган саен, нурлар тула,
Ак чәчәккә дөнья күмелә.

Йөз әле син
Ап-ак хыялымда,
Бәхетеңә мәңге кагылмам!
Мин аккошлар сөям,
Бер сокланып
Үтен китәрмен дә яныңнан
Югалырмын
Офыкларга кереп,
Күзләреңә бүтән күренмәм.

Ак чәчәкләр сулып кибәр кебек,
Китә күрмә, аккош, күлеңнән!

«ШӘҺРИ КАЗАН» – СИНЕҢ ӨЧЕН, СИНЕҢ ТУРЫНДА
8 (917) 851-69-62

Шәһри Казан
ИНДЕКСЛАР
П2395 (3 тапкыр чыга)
П2430 (пәнҗешәмбе саны)
П2419 (оешмалар өчен)
www.shahrikazan.com

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ (НӘШЕР ИТҮЧЕ) – «ТАТМЕДИА» АҖ
«ТАТМЕДИА» АҖ ФИЛИАЛЫ ҖИТӘКЧЕСЕ –
БАШ МӨХӘРРИР ГӨЛНАРА ИЛЬЯС кызы САБИРОВА.

© Газетада басылган язмаларны файдалану, шулай ук өзекләр китерү өчен, «ШК» редакциясеннән язмача рөхсәт алу мәҗбүри. Редакциянең фикере авторларның фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин. Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк. Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы.

РЕКЛАМА ХЕЗМӘТЕ
Тел: (843) 562-50-12,

ХАТЛАР БҮЛЕГЕ
Тел: (843) 562-50-03,
E-mail: shahri-kazan@tatmedia.com

НӘШРИЯТ
«Татмедиа» АҖ
420097, Казан, Академия ур., 2

16+
Сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 5719
Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
Заказ 677. Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәттә (Роскомнадзор) 2012 елның 27 августында ПИ №ФС77-50970 нче теркәлү таныклыгы алды. Газета атнага 3 тапкыр – сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә чыга. График буенча бу санга 17 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 17 сәгатьтә.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ
420066, Казан,
Чистай ур., 5 нче йорт
Тел.: (843) 562-50-12,
факс: (843) 562-50-07

БАСМАХАНӘ
420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы